Миргарифан Мирихан улы,

Назиф Мириханов

# Нәсел. Заман.

Урсай - 1975,

Мәскәү - 2024.

М. Мирихан улы, Назиф М.
Нәсел. Заман. (80 б.) – Урсай, Мәскәү: 1975, 2024.

Миргарифан Мирихан улы (М.М.) Мирихановның (1903-1977) гарәб алфавитында татар телендә язылган хезмәте. Урсай аулы, Азнакай районы, Татарстан Республикасы, 1975.

Әхмәт Абдурахман улы Галимов (1928-2024), Ульян өлкәсендә туган журналист. Текстны гарәб графикасыннан кирилл алфавитына кулдан күчереп язды. - Мәскәү, 2015 ел.

Назиф Мөҗәһидән улы (Н.М.) Мириханов (1952) искәрмәләр, белешмәләр һәм азакта өстәмәләр белән төп текстларны саклап  компьютерда язды.
- Мәскәү, ноябрь-декабрь, 2024 ел.

Фәнис Миргарифан улы Мириханов (1945) биргән мәгълүматлар кулланылды. Урсай - Казан, 2003 ел.

Бу хезмәтне туплап бастыру Ильнур Назиф улы Мирихан (1979) инициативасы буенча башкарылды. Мәскәү - Казан.

Эчтәлек

1. Кереш сүз . 4
2. Нәсел башы: Гираит би (15 гасыр), Нугай Урдасы. 5
3. Нугайбәк Хәсәнов (1736-1802), 8
Пугачёв фетнәсе атаманы. Аның тугыз улы.

4. Җәркәй. 10
5. Җармөхәммәд. 11
6. Шәмсетдин ахун. 13
7. Хөрмәкәй, Шәңгәрәй, Солтангәрәй кантун-дворяннар.
Башкорт - мишәр казаклары. Генерал Нугайбәковләр. 16
8. Шаммаз. 21
9. Морадым. 22
10. Котлызаман. Ардинат һәм Ренат Нугайбәковлар. 23

11. Габделваһаб. Нурлыбанат әби, пр. Галиуллин З.Т. 25
12. Сәлтәш - Әхмәтхан - Мирихан (1853-1914). 29
13. Мирихан тармагы. 33
14. Назиф Мириханов сәхифәләре... 40
15. Миргарифан Мирихан улы (1903-77) тормышы. 43
16. Мөҗәһидән Мириханов (1927-2001) тормышы. 60

17. Гәзизулла Кәрамуллин (1927-2009) тормышы. 65
18. Миңнулла Нәбиуллин (1898-1987) тормышы. 73

19. Йомгак. 78
20. Әдәбият. 79

Кереш сүз.

Миргарифан бабай 1976 елны үз язмаларын миңа бераз гына укып күрсәтте. Өйрәнелгән студент гадәте буенча мин тиз генә конспект итеп язып алдым. Язмалар белән тулысынча танышуым 1981 елны киленебез Гөлфая Кәрамуллина гарәб алфавитыннан кириллицага күчергәч кенә булды. Миндә Гираит (Гираят) би Һәм Нугайбәк шәҗәрәләре (родословные) бик тирән тәэсир калдырды. Аларда язылган вакыйгалар, халыклар, дәүләтләр турында тарих һәм этнология буенча фәнни һәм публицистик әсәрләрне максатчан өйрәнә башладым һәм 1999 елда “Нәсел - Род” дигән рус телендәге кулъязмамны бастырып ротопринтта күбәйтеп туганнарга, нәселдәшләргә, галимнәргә, дусларга тараттым. Ул китапны чыгаруым Миргарифан бабайның вәсиятен үтәү булды.
2015 елда гарәб алфавиты белгече Ә. Галимовның Миргарифан бабай язмаларын өйрәнү нәтиҗәләрен  кабат укыганда төп игътибарым Бабайның үз тормышына багышланган бүлеккә төште. Ул бит борынгы заман белән бергә башыннан үткәннәрне, илдә барган сәяси-җәмгыяви вакыйгаларны бәйләп, уникаль әсәр тудырган икән. Шәҗәрә  бит ул исемнәр һәм алар арасындагы сызыклар гына түгел. Шуңа күрә, бу китапта күпчелек игътибар биографияләргә, язмышларга, бигрәк тә, бабаларыбыз һәм кардәшләребез тормышына  бирелде. Миргарифан бабай үзе язган текстлар тулысынча диярлек сакланды.

Н.М.

Нәсел башы: Гираит би, Нугай Урдасы.

Бу язуны язучы Миргарифан Мирихан углы (М.М.).
Нәсел-нәсеп Нугайбәк бабайдан югары кем углы? Мин бу сорау белән бик яшли кысыксына башладым. Аулда берничә шәҗәрә (нәселебез агачын) язып баручы бар иде. Беренче язуым Хисамиев Камалетдиннан, икенче язуым Монасыйп Мәрданша углы Нугайбәковтан булды.
1881 елның 11 июнендә мөәзин Мөхәммәдхафиз (1858-1930) Әбелфәттах углы әл-мәрхүм Нугайбәков язган: мелла (укымышлы кеше) Әбелфәттах мелла Хәлилулла углы, Хәлилулла мелла Шәмсетдин ахун углы, Шәмсетдин Нугайбәк углы, Нугайбәк Хәсән углы, Хәсән Урсай углы, Урсай Җийаш углы, Җийаш Истангол углы, Истангол Сарыбай углы, Сарыбай Бүләк углы, Бүләк Аккүз углы, Аккүз Арслан углы, Арслан Алганчы углы, Алганчы Куганчы углы, Куганчы Гираит би углы.
Гираит би (15 гасыр) - Нугай кешесе.
Н.М.: Нугай, (- Иле, - Йорт) тарихта күпчелек Нугай Урдасы (Ногайская Орда) дип бирелә.15 гасыр башында Алтын Урда дәүләте тарала башлагач Нугай Урдасын Идегәй би нигезли. Казан ханбикәсе Сөембикә Нугай Иле җитәкчесе Йосыф би кызы. Йосыф би улларыннан Россиядә князь Юсуповлар нәселе башланган. Нугай Урдасы башкаласы Сарайчык хәзер Казакъстан җирендә.
М.М.: Хиҗри (ислам календаре) буенча 1049-нче елдан Имән-кала Уфа дип атала башлый (якынча 1671 ел).

Н. М.: Имән-кала - Уфа Нугай Урдасына кергән, улус башкаласы булып торган. 18 гасырда Нугай Урдасы әкренләп Россия империясенә кушылып бетә.
М.М.: Гираит бинең кайбер нәсел дәвамчылары (16 гасырда) Уфадан күчеп китә башлый. Алар Әҗми тирәсендә Наратлы чокыр дигән җирләрдә тормыш иткәннәр. Аул Истангул углы исеме белән Җийаш (Дияш) дип йөртелә башлый. (Хәзерге Башкортостанның Бакалы районы). Соңрак Гираит би нәселе Кәрпи елгасы буена утырган. Шул ук вакытларда Пасмараудан Кәрпи (Костромадан (?) Карпов) дигән бер баяр да килеп күрше җирләрне үзләштерә башлый. Аңа ул җирләрне патша бүләк итә. Кәрпиев баяр үз кул астына күп кенә рус крәстиәннәрен туплап, Ык елгасын буып, күлдән күлгә чокыр (канау) казытып тегермән кордыра.
Баяр белән мәслихәтләре китеп Урсай бабай Җийаш  углы үзенең кәвеме белән 1660-нчы еллардан соң башта Ык елгасының тау кырласына, аннан соң югары ягына утырган. Бу урыннан ерак түгел Җүкәле Түбә дигән җирдә җүкә (юкә) урманы булган. Өйләрне шул урманнан ясаганнар. Урсай бабай янына Исхак, Бикәй, Карач, Кыдрач, Минай бабайлар һәм тагын берничә нәсел типтәрләр килеп урнашкан. Урсай аулы үсеп киткән. Урсай бабай 1698 елда үлгән.
Н.М.: Бу язмаларны әзерләгәндә Урсай исеме буенча бер фаразга (версиягә) тап булдым. Нугай Иле төркиләрендә Ырыс-(Урус-) исеме очрый. Мәсьәлән, Нугай Урдасыннан чыккан Урус (Ырыс - Рысь) бидән, русның князь Урусовлары

барлыкка килгән. Бу исем төркичә “-ай” кушымтасы белән әйткәндә Урусай, Урсай килеп чыга. Документлар буена Урсай аулының атамасы 1707 елда Урусай булган, ә рус сәүдә кәгазьләрендә (1775) Рысай дип күрсәтелгән (7, с.88). Миргарифан бабай язмаларында Хәсән Урсай улының һәм Нугайбәк Хәсән улының тормыш юллары күрсәтелми, шул исәптән Нугайбәк турында легендалар да юк. Алар Чалпы аулы тарихында язылган. Мин үземнең “Нәсел -Род” (1999) кулъязма китабымда Хәсән һәм Нугайбәк, Пугачёв фетнәсе турында шактый гына мәгълүмат урнаштырган идем инде. Монда бераз гына әйтеп үтәм.

Хәсән Урсай улы, шул тирәдә патша тарафыннан ата-бабаларына беркетелгән җирләр булганга, бер төркем кардәшләре белән 1704 елда Чалпы аулына килеп төпләнә, Чалпы, Урсай, Тымытык һ.б. аулларның  старшинасы булып тора (7, 58). Земский агроном ярдәме белән игенчелек тармагын үстерүгә күп көч куя. Чалпы аулы янындагы иген кырлары хәзер дә ”Әсән басуы” дип йөртелә. Хәсән байның төп кәсебе сәүдә (торговля) була. Ул мал-туар төяп Оренбург ягына бик күп кәрвән (караван) йөрткән. Өяз, өлкә (уезд, губерна) түрәләре белән эшлекле мөнәсәбәтләр кора белгән.

Нугайбәк бабайга кадәр булган нәсел агачыбызның турыдан-туры ирләр тармагы түбәндәгечә килеп чыга: Гираит би (15 гасыр) - Куганчы - Алганчы - Арслан - Аккүз (Ваккас?) - Бүләк - Сарыбай - Истангол - Җийаш - Урсай – һәм Хәсән – Нугайбәк (18 гасыр).

Нугайбәк (1736-1802) Хәсән углы. Пугачёв фетнәсе атаманы.

Самарада гимназиядә укый. Әтисе Хәсән үлгәч берничә аулга старшина булып кала, Чалпыда яши.
1773-74 елларда атаман буларак Пугачёв фетнәсендә катнаша. Нугайбәк Әсәнов (Асанов, Хәсәнов) төркеме хәзерге Азнакай, Минзәлә, Зәй, Әлмәт районнарында һәм Башкортосанның Бакалы районында хәрәкәт итә. Зәй кирмәнен алганда төркемнең саны 900 кешегә җитә. Патша гаскәрләре тарафыннан эзәрлекләнеп килгән Нугайбәк төркеме Югары Стәрле аулы янында тар-мар ителә һәм калган кешеләре белән Бакалы ягына чигенә. Фетнә бастырылгач Нугайбәк качуда йөри, Әби-патша тарафынан ярлыкау (амнистия) чыккач өенә кайта.
Тарихи документларда 1782 елда инде Нугайбәк Әсәнов Юрми волосте старшинасы итеп күрсәтелә: Уфа өязе, Казан даругасы, Оренбург губернасы (7, с.89). (Чалпы, Урсай аууллары Тымытык волосте, Бөгелмә өязе, Самар губернасына 1851 елдан гына керә башлыйлар).
25-30 ел саен кабатланып торган башкорт фетнәләреннән (“Башкирские восстания”-дән) тәмам туйган патша хөкүмәте Пугачёв явыннан соң 1798 елны хәрби-административ территорияләргә - кантоннарга бүленгән башкорт-мишәр казак үзидарә системасы оештыра. Безнең бабайлар һәм төбәк 12-нче кантонга керә. Чалпы, Урсай аулларыннан тыш бу кантонга  Тымытык, Азнакай, Югары Стәрле аулларыда да керә. Башкорт-мишәр казак системасы Нугайбәк исән

вакытта оештырылып ныклап безнең Сәлтәш - Әхмәтхан бабаларыбыз заманында көчендә булып 1864 елга кадәр дәвам итә.

Нугайбәк бабай һәм аның улларының (шул исәптән, Мириханның бабасы Сәлтәшнең) Чалпыдагы каберлеге бик яхшы карлган, уратып алынган, төрбәләр куелган. Бу эшне Котлызаман Нугайбәков тармагыннан булган атаклы нефтче, хәйрияче Ардинат әфәнде Нугайбәков башкарды.

Миргарифан бабай язмаларына кайтабыз.
М.М.:Нугайбәк бабамызның угланнары тугыз булган:

1-нче углы - Җәркәй Нугайбәк углы (1751-1773),
2-нче углы - Җармөхәммәд Нугайбәк углы (1758-1833),
3-нче углы - Шәмсетдин Нугайбәк углы (1769-1848),
4-нче углы - Хөрмәкәй Нугайбәк углы (1761-1830),
5-нче углы - Сәлтәш Нугайбәк углы (1766-1834),
6-нчы углы - Шаммаз Нугайбәк углы (1770-1842),
7-нче углы - Морадым Нугайбәк углы (1764 ),
8-нче углы - Габделваһаб Нугайбәк углы (1779-1844),
9-нчы углы - Котлызаман Нугайбәк углы (1768-1829).

Нугайбәк бабайның угыллары (18-19 гасырлар) бик укымышлы булганнар, кайсы мулла, кайсы ахун, кайсы кантун, кайсы өяз башлыгы булып торган. Алар барысы да Нугайбәков фамилисен йөрткәннәр.

Җәркәй Нугайбәковтан таралган балалар

Җәркәй (Яркәй) бабайның (1751-1773) угыллары, беренче хатыннан: 1 -Бәләкәй Гәрәй, 2 -Хәлиулла, 3 -Галиәкбәр, 4 -Миһран - углы җук (юк); икенче хатыннан: 5 – Әхмәтсәгыйт. Җәркәй бабайның бер кызы билгеле - Балагай.

1. Бәләкәй Гәрәй угыллары: Фәхретдин, Насретдин; Фәхретдин углы Шәйхетдин, аның углы Габдулла; Насретдин углы Шәехгариф.

2. Хәлиулла угылы Төхфәтулла, аның угыллыры: Рәхмәтулла, Зиннәтулла, Мөхәммәтгәрәй. Мөхәммәтгәрәй угыллары: Шәңгәрәй, Әхмәтҗан, Әхдиҗан.
Н.М.: Шәңгәрәй кызлары Зәйнәп, Хөббениса һәм Әхмәтҗан уллары Зәкиҗан (1915), Галимҗан (1939) Пермдә яшәделәр.
Әхдиҗан тармагы -Мөхәммәтҗан -Дәүләтгәрәй -Мөхәммәддариф -Мирдасиг (Мирза-). Мирзасигның уллары Мөсәгыйт һәм Фәрәгат. Мөсәгыйтнең улы Латиф. Фәрәгатнең кызы - Нәфисә, улы Фирдәвес - Казанда Оргсинтезда эшли.

3. Галиәкбәр угыллары: Галиәхмәт, Мордахан (Морза-), Галиәскәр, Сираҗетдин. Галиәхмәт углы Кадыйхан.
Мордахан  угыллары: Мөхәммәтдин, Галиулла.
Галиәскәр угыллары: Дөлкарнәй, Дөлкафил (Зөлкарнәй, Зөлкафил) сугышта үлгәннәр.
5. Әхмәтсәгыйт угыллары: Сибгатулла, Сабирҗан,

Мөхәммәдшәриф, Дакирҗан (Закир-) - сугышта үлгән. Сибгатулла угыллары: Миңлеәхмәт, Камил. Сабирҗан углы Аксак Галимҗан. Яңа Урсай Мөхәммәдшәриф угыллары: Әхмәтлатыйф, Мөхәммәтлатыйф.
Җәркәй кызы Балагай Фәхретдингә кияүгә чыга. Аларның угыллары: Фаралдин һәм Насретдин. Насретдин угыллары Шәйхетдин һәм Шәехгариф, Шәйхетдин углы - Габдулла.

Җармөхәммәд Нугайбәковтан таралган балалар.

Җармөхәммәт (Ярмөхәммәт, 1758-1833) - башкорт-мишәр казак системасында  походный старшина, аның угыллары, беренче хатыннан:1 - Мөхәммәдияр, 2 - Гали хәзрәт (Али бай, 1800-1848), 3 - Кыргызгәрәй; икенче хатыннан: 4 - Хәбиберрахман.
Җармөхәммәтнең Бибимәрҗән исемле кызы билгеле.

1. Мөхәммәдияр углы Ибраһим бине Яремәк 1830 елны Бохара мәдрәсәсендә укып кайтып Чалпыда мулла булган.

2. Гали хәзрәт Чалпыда яшәгән, аның уллары: Габделлатыйф, Габделфәттах, Әбелмөнних, Әбелхарис - углы җук. Габделлатыйф угыллары: Галәүэтдин, Саләхетдин, Кәшшафетдин. Галәүэтдин углы Габдрахман сугышта үлгән. Саләхетдин углы Миргалим. Кәшшафетдин углы Габделәхәт. Габделфәттах укытучы булган, “Аксак мулла” дип йөрткәннәр. Габделфәттах угылы Асафетдин, аның

угыллары Мөхәммәтгариф, Мөхәммәддариф сугышта үлгәннәр. Әбелмөнних углы Вагыйз.
3. Кыргызгәрәй тармагы: - Мөхәммәдкасим - Мөхәммәдхафиз - Мөхәммәддакир (-закир).

4. Хәбиберрахман угыллары (берничә хатыннан): Мөхәммәдшәриф, Дәүләтша, Дәүләтгәрәй,Мөхәммәдгәрәй. Мөхәммәдшәриф угыллары: Мөхәммәдгариф, Мөхәммәдшакир. Мөхәммәдгариф угыллары: Мөхәммәдсалих, Миргасыйм, Мөхәммәдсалих угыллары: Миргадийан (-зиян), Мөҗәйдән, Миргариф. Миргариф угыллары: Наил, Нияз.
Дәүләтша угыллары: Җиһанша,
Әхмәдиша. Җиһанша тармагы - Сәйетша - Вәлиша.
Дәүләтгәрәй углы
Мөхәммәдгәрәй угыллары: Шәңгәрәй, Әхмәтҗан, Әхмәтхан. Әхмәтҗан улы - Мөхәммәтҗан, Әхмәтханнан ике ир бала бар.

Үз заманында Россиянең Баш мөфтие булып торган Ризаэтдин Фәхретдиновның (1859-1936) Петербург архивында саклана торган язмаларында Гираит би, Нугайбәк шәҗәрәләре бар. Шул язмалар арасында Чалпы аулыннан Ярмөхәммәт Нугайбәковның кызы Бибимәрҗәннең  Ризаэтдин хәзрәтнең туган аулы Кичү-чаттагы бертуганы Фәсхетдингә кияүгә чыгуы билгеле. Хәзерге вакытта Әлмәт районының Кичү-чат аулында иганәче Ардинат Нугайбәков көче белән оештырылган Риза Фәхретдин музее эшләп килә.

Шәмсетдин ахун Нугайбәковтан таралган балалар.

Н.М.: Шәмсетдин (1769- 1848) - Нугайбәкнең ахун, шәех (шейх), суфи дәрәҗәләре алган бердәнбер улы. Уфа губернасының Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укыган. Урсайның иске зияратында җирләнгән.
Шәмсетдин ахунның хатыны Хәмидәдән (1773) угыллары: Хәлилулла мулла һәм Абдулгафар мулла (1810-) – Петербург Аерым гвардия корпусының гаскәри имам-хатибы, хәрби медальләр белән бүләкләнгән. Хатыны - Бибиарифә Шайнул-Абдинова, 1861 елгы кызлары булган.
Абдулгафар мулла Нугайбәковның биографиясе Саратов губернасының (Зур) Чирекле (Черкиле?) аулы белән бәйле (7, с. 104). 1881 елда Сәлтәш тармагыннан булган галим Гимад Нугайбәков та , бераз буталган мәгълүмат буенча, шул аулда туган (7, с. 400)?

Хәлилулла (1802-1855) Шәмсетдин улы - Урсайның җәмигъ мәчете имамы. Уллары, беренче хатыны Фатимадан (1806): 1 - Әбелфәтих, 2 - Әбелфәттәх, 3 - Сәетбаба, 4 - Дәүләтша; икенче хатыны Бәдернисадан (1809) : 5 - Абдулсабур, 6 – Абдулшәкүр, 7 - Әфләтун.
1. Әбелфәтих, хатыны - Хәбибҗамал Шамиратова (1835). Уллары: Мирхәйдәр, Мөхәммәдгариф, Мөхәммәдшәриф мулла, Мөһәммәдзәки (1914 елгы сугышта үлгән), Мортаза (1857), Чулак (кулы зәгыйф) Фаттах - беренче булып Ык елгасында тегермән корган.
2. Әбелфәттәх (1827) - имам, хатыны – Бибишаһисафа

Усманова (1833). Уллары Мөхәммәдхафиз (1858) һәм Мөхәммәдзакир(1871). Мөхәмәдхафиз - мөәзин, бу “Нәсел” язмасының 19 гасырда төп нөсхәсен язган кеше.
Мөхәммәдхафиз (Хафиз) мөәзин угыллары: Мөхәммәдгариф, - Мөхәммәдфазыл, Сөләйман.
Мөхәммәдзакир (Закир) мулланың ике хатынынннан балалары: Бибимәхзүмә (1897), Мәгъмүрә (1901), Габдулла (1903), Бибимөкаддәсә (1908), Мөхәммәдабрар (1910), Мөхәммәдәсрәр (1915), Әнвәр (1917), Әсхәт (1921), Әзһәр (1924), Фәүзилҗинан (1927).
Бертуган Хафиз мөәзин һәм Закир мулла Нугайбәковлар (ГПУ-ның) кулаклар исемлегенә эләгәләр. 1930 елны Хафизны кулга алып Казанда атып үтерәләр, Казанның Архангельски зияратында күмелгән. 1931 елны Закир мулла раскулачивать ителә, бөтен милкен тартып алып урамга куып чыгаралар (7, 263). Кулга алганнарын көтмичә бәләкәй арба тартып балаларын алып төнлә Урсайдан чыгып качалар, кардәшләре яшәгән ерак башкорт авылына барып урнашалар. Закир абзый көтү көтеп бик йомык тормыш алып бара. Аның улы - Закиров Әзһәр (1924, Урсайда туган), Әзһәрнең кызы - Рәсимә (1949). Рәсимә Мусина (Нугайбәкова) - Уфада “Пышка- Кабартма” сәүдә-кулинария челтәрен оештыручы һәм хуҗасы. Урсайда Мөхәммәдзакир муллага багышланган мәчет төзүдә катнашты. Рәсимә ханымның кызы Зилә, оныклары Максим
һәм Даниэль Германиядә яшиләр (7).

3. Сәетбаба улы Сәхибгәрәй, аның уллары Әхмәтгәрәй һәм Арслангәрәй. Әхмәтгәрәй уллары Мөхәммәдфазыл һәм Мөхәммәдсалих.
4. Дәүләтша улы Сәгъди мулла. Аның уллары: Мөхәммәдшәриф мулла, Габдрахман, Мөхәммәдгариф. Мөхәммәдшәриф уллары: Фәтхелбаян, Бәгис, Нурлыгаян, Мөхәммәдфатих – аның улы (кече) Фәтхелбаян.
5. Габделсабур мулла (1848), аның улы - Мөхәммәдсабир.
6. Габделшәкүр мулла (1843), аның уллары: Мөхәммәдшакир, Хәбибулла. Мөхәммәдшакир улы Фәтих 1914 елгы сугышта үлгән.

7. М.М.: Әфләтун угыллары: Шаһимәрдән, Арыслан, Әмирҗан, Диннур (Зиннур). Арыслан углы Гәрдан (Гардебамирхан). Әмирҗан угыллары Илдархан һәм Миргадийан. Илдархан угыллары: Мирдахан, Бадакшан, Фәтхелләбиб. Шаһимәрдән һәм Диннурның угыллары җук.

Н.М.: Шәмсетдин ахунның турыдан-туры ике генә улы булып, күпчелек кызлар туган: Сәрвиҗиһан (1800), Бәдриҗиһан (1806), Нәмерҗиһан (1808), Фәхрисорур (1810), Гайниҗиһан (1814), Бибиаклимә (1825).

Шәмсетдин ахун шәҗәрәсе И. Имангулов китабыннан тулыландырылды (7). Чөнки Илшат әфәнде Рәсимә ханым Мусина (Нугайбәкова) соравы буенча бу тармакны ныклап өйрәнгән язучы, журналист. Гираит би һәм Нугайбәк шәҗәрәләре буенча белгеч. Элемтә:  il.iman@yandex.ru , тел./вац. 8-917-409-31-47.

Хөрмәкәй Нугайбәковтан (1761-1830) таралган балалар. Н.М.: Хөрмәкәй -Шәңгәрәй -Солтангәрәй кантуннар, дворяннар. Генерал Измаил һәм Руслан Нугайбәковләр.

М.М.: Хөрмәкәй Нугайбәк улы 1820 елга кадәр кантун (кантон башлыгы) булып яшәгән. Хөрмәкәй кантун углы Шәңгәрәй (Шаһингәрәй, 1799-1878) әтисенең эшен дәвам итеп 1820-64 елларда кантун булып торган. Н.М.: Хәрби хезмәтен гади казактан башлый, есаул, походный старшина, хорунжий була. Кантон башлыклары Оренбург генерал-губернаторына буйсынганнар. М.М.: Кантун үз кулы астында патша казнасы хисабына күп кенә армия тоткан. Хөрмәкәй кантун Урсайның иске зияратында җирләнгән.

Н.М.: Оренбург өлкәсенең беренче губернаторы И. Неплюев 1743 елда башкорт һәм мишәрләр өчен казак рәвешендә чик саклау хезмәте кертә (8, с.200). 1798 елдан
Рус империясенең көньяк-көнчыгыш чикләрендә яшәүче башкорт һәм мишәрләр белән идарә итү өчен кантон административ-территориаль казак гаскәре системасы оештырыла. Өстән төшерелгәнгән манифестлар, карарлар, документлар гаскәргә татар диалектында (ул вакыттагы иске татар әдәби телендә) җиткерелә (7, с.110). Н.М.: Башкорт-мишәр казак идарә системасының күпчелек татар әдәби телендә алып барылуы җирле төрки сөйләмнәрнең, шул исәптән башкорт теленең дә, татар теленә тагын да якынаюына нигез була. Кантон системасына хәзерге Пермь, Екатеринбург, Оренбург, Самар, Сарытау өлкәләре,

Башкортостан тулысынча һәм Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарын үз эченә ала. 11-нче кантонга Оренбург өлкәсенең Минзәлә уезды, Вятка өлкәсенең Алабуга һәм Сарапул уездлары керә.
Бер-бер артлы Хөрмәкәй һәм Шәңгәрәй 1798-1864 елларда идарә иткән 12-нче кантонга ул вакыттагы Оренбург өлкәсенең Бәләбәй, Богырыслан, Бөгелмә уездлары кергән. Бөгелмә уездының Азнакай, Тымытык, Урсай, Чалпы, Югары Стәрле һәм башка ауллар кантонлык кул астында булган. Казак-кантон системасына, шулай ук, хәзерге Мөслим, Баулы районнары ауллары кергән. 12-нче кантон 20 мең ир-ат яши торган 250 аулны берләштергән 25 юрттан торган. Кантонның идарә үзәге Бәләбәй өязе Шланлыкүл аулында була. Юртлар белән юрт старшиналары, сотниклар, десятниклар идарә иткән. Башкорт-мишәр казаклары Рус империясе алып барган барлык сугышларда катнашканнар. 1812-15 еллардагы Наполеон белән сугышта Азнакай (Чалпы, Урсай) казаклары Германиягә кадәр барып җиткәннәр. Патшага яхшы хезмәтләре өчен Хөрмәкәй һәм Шәңгәрәй кантуннарга нәселдән күчә торган дворян дәрәҗәсе бирелгән. Шәңгәрәй кантон “Изге Станислав” ордены һәм көмеш медаль белән бүләкләнгән (2,7,8).
1864 елда кантон башкорт-мишәр казак гаскәре системасы бетерелә, казак хәрби һәм административ җитәкчеләр МВД карамагына күчерелә. М.М.: 1871 елның үктәбер аеннан башкордтан солдат алына башлый, 21 яшендәгеләр.

М.М.: Хөрмәкәй Һәм Шәнгәрәй кантуннар бик күп болын әрәмәлек, урманнарны үз кул асларында биләп торганнар. Шәңгәрәй Нугайбәковның  өч поташ заводы, ике тегермәне булган.

Хөрмәкәй кантун угыллары: Шәңгәрәй кантун һәм Гимадел. (Н.М.: Башка чыганакларда тагын берничә улы күрсәтелә: Дәүләтшаһ (1789-1830), Әфләтун (1808-)...; Гимадел - Гадел, Равил дип тә бирелә?  Хөрмәкәйнең өч хатыны булган). Гимадел углы Мирихгәрәй, аның угыллары: Салихҗан, Насыйрҗан, Мөһәммәдгариф – дворян булган. Салихҗан углы Әмирҗан, аның углы Габбасҗан Ватан сугышында үлгән.

Н.М**.: Шәңгәрәй** кантун (1796-) угыллары: 1 - Әхмәтгәрәй (1839-), 2 - Солтангәрәй,  3 - Әхмәтмохтар, 4 - Әсмәндияр. Шәңгәрәйнең беренче хатыны Бибисара Усманова - обер-офицер кызы; икенче хатыны Шәмсениса - дворян нәселеннән, 1814 елдан кантон башлыгы булып хезмәт иткән Баязит Солтанов (-1823) кызы.

1. Әхмәтгәрәй казак гаскәрендә урядник булып хезмәт итә. Аның угыллары Сәригъгәрәй һәм Бәхтигәрәй. Сәрыйгъгәрәй тармагы: - Искәндәр - Мөхәммәдтәкый. Бәхтигәрәй угыллары: Батыргәрәй,  Нурмөхәммәд, Галимәрдән.

2**. Солтангәрәй** - казак, Неплюеевский кадет корпусын бетерә, 1854-63 елларда 4-нче һәм 22-нче **кантон башлыгы** булып хезмәт итә (7, с.115). Димәк, Хөрмәкәй тармагы өч буын кантуннар:  Хөрмәкәкй – Шәңгәрәй – Солтангәрәй.

3. Әхмәтмохтар тармагы: - Измаил (1896-) - Руслан (1930-).

Шәңгәрәй кантун оныгы –
Совет Армиясе **генерал-**лейтенанты **Измаил** Әхмәтович **Нугайбәков** (1896-1959). Дворян нәселеннән, Перм өлкәсе Шадринск шәһәрендә штабс-капитан Әхмәт Гәрәевич (Әхмәтмохтар Шәңгәрәевич) Нугайбәков гаиләсендә туган. Патша армиясендә атлы гаскәрдә прапорщик, поручик була, “Георгиевский крест” белән бүләкләнә. 1917 ел азагында Петроградка татар-мөселман полкына килә, полк командиры ярдәмчесе була. 1926-29 елларда Мәскәүдә Хәрби Академиядә укый. 1938 елда “халык дошманы” буларак кулга алына, 1940 елда аңа карата эш туктатыла һәм И. Нугайбәков армия сафларына кайтарыла. Казан танк училищесы башлыгы урынбасары итеп куела. 1942 елдан фронтта, авыр яралана. Танк корпусы, дивизиясе штаб башлыгы була. 1944 елда генерал дәрәҗәсе бирелә. Сугыш беткәч 1950 елга кадәр Германиядә калган совет гаскәрендә хезмәт итә. 1950-54 елларда Артиллерия югары мәктәбен җитәкли. Отставкага чыккач Курскта яши, шунда Никитинский зияратында күмелгән. Сигез орден белән бүләкләнгән, шул исәптән “Ленин” һәм өч “Кызыл Байрак” орденнары. (7, с.394-98).

Генерал улы генерал дигәндәй, Измаилның улы Руслан (1930-) да Әтисе һөнәрен сайлап хәрби хезмәттә **генерал-**майор дәрәҗәсенә җитә. **Нугайбәков Руслан** Измаил улы

рече офицер хезмәт баскычларын узып 1953-58 елларда Хәрби Академиядә укый, аннан ракеталар полкы командиры, Төньяк махсус гаскәрләр берләшмәсе командующие була. 1986 елдан Оборона министрлыгының укыту үзәге башлыгы булып хезмәт итә. Отставкага чыккач Мәскәүнең “Пресненский” районында Гражданская оборона бүлеген җитәкли. Мәскәү татар җәмәгатьчелеге активисты булып тора. (20, с. 42).

Хөрмәкәй кантун кызлары: Хәбибҗамал, Миңнесафа (1800-) шәмсевафа (1801-), Шәмсеҗиһан (1806-), Мирвафа.

Хөрмәкәй кызы Мирвафа (1803-) Нугайбәкова  Бәләбәйдә дворян нәселеннән булган Шаһимәрдән Сыртлановка кияүгә чыга (8, с. 353...). Бәләбәйдә туып үскән Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланова да шул нәсел белән бәйле булырга мөмкин? Заманында аны пролетар тамырдан булмаганы өчен вуздан куалар. Мәгубә авиаклубка языла, очучы (лётчица) булып китә. Сыртланова Мәгубә (позывное - “Марта”) Хөсәен кызы (1912-1971, Казан) – Ватан сугышы вакытында хатын-кызлар төнге бобардировщиклар (“ночные ведьмы”) авиполкының командир урынбасары була.

Шаммаз Нугайбәковтан  таралган балалар.

Шаммаз (1770-1842, Чалпы) казак гаскәрендә есаул була. Хатыны Гөлсылу (1784), угыллары: 1 – Мөхәммәтҗан (1809), 2 – Мәрдәнша, 3 - Шаһиморат.
Кызлары: Гөлйөзем (1801), Гөлбаһирә (1802), Хөсниасма (1807).

1.Мөхәммәтҗан казак гаскәрендә хорунжий була, аның дүрт баласы яшли үлеп бетә.

2. Мәрдәнша угыллары: Монасыйп, Гыйрфан, Мөхәммәтдариф, Госман.
Н.М.: Монасыйп Мәрданша улы Гираит би һәм Нугайбәк шәҗәрәләрен төзүче-авторларның берсе.
Монасыйп угыллары Миргасыйм һәм Габдрахман.
Гыйрфан углы Солтангәрәй патша хезмәтендә үлгән.
Мөхәммәтдариф углы Мөхәммәтгариф. Госман угыллары Мөхәммәдхан һәм Миңнехан.

3. Шаһиморат угыллары: Зәңгәр Фәхретдин, Шәрафетдин, Кәшшафетдин.
Зәңгәр Фәхретдин угыллары Шаһимәрдән һәм Мирдасалих.
Шәрәфетдин тармагы: - Сәлахетдин - Хәләфетдин - Ләис.
Кәшшафетдин угыллары: Миңнесәгыйр, Кәмалетдин, Шәмсетдин, Сукыр Баһау. Шәмсетдин тармагы: - Сәләхетдин - Мирфаяз (1956). Мирфаяз озак еллар Бөгелмәдә “Водоканал” Башлыгы булып эшләде.

Морадым Нугайбәковтан таралган балалар.

Морадым угыллары: 1 - Могътәсим, 2 - Мозаффар һәм 3 – Мөхәммәткәрим – ир баласы җук (юк).

1.Могътәсим угыллары: Мөхәммәдшаһ, Габдулла, Игътисам, Әхмәтҗан, Мөхәммәдҗан.
Мөхәммәдшаһ угыллары Сәетшаһ һәм Хәйрелгабидин.
Габдулла угыллары Хәбибулла һәм Хәмидулла.
Игътисам углы Газизҗан, аның угыллары Өлфәт һәм Рифкат, кызы Фирүзә. Н.М.: Рифкат Азнакайда мәктәп директоры булып эшләде.
Әхмәтҗан углы Мөбәрәкҗан.

2. Мозаффар углы Мөхәммәдгәрәй. Мөхәммәдгәрәй угыллары: Әхмәтлатиб, Асылгәрәй, Миргасыйм, Мирдаһит - (-заһит) сугышта үлде. Әхмәтлатиб углы Мәүлетдин. Асылгәрәй углы Миргадийан (-зиян). Миргасыйм угыллары Миргаяз һәм Мирдасалих сугышта үлделәр.

________________

Н.М.: Исемнәрне язам-язам да уйлап куям. Безнең класста Миргалимов Мигазиян белә Миргазиянов Мирмәгъсүм Мирхафизан улы бар иде. Боларның исем-фамилияләре безнең якта аеруча еш очрый торгннардан. Аларның тышкы кыяфәткләрендә дә җирле үзенчәлекләр бар иде. Нәселдәшләр булмадык микән?

М.М.: Котлызаман Нугайбәковтан таралган балалар.
Н.М.: Ардинат, Айрат, Гөлшат, Ренат Нугайбәковлар.

Котлызаман (1768-1829) угыллары: 1 - Сәетбаттал, 2 - Хәсән (1798) , 3 - Габделгазиз, 6 - Солтангәрәй, 4 – Габделрәкыйб, 5 -Хәмидулла.
Кызы - Ситдикә (1803). Хатыны – Латифа (1768).

М.М.: 1. Сәетбаттал угыллары: Габдесәлам, Габделсаттар. Аларның ир балалары җук (юк).

2. Хәсән урядник булган, аның углы Габдулла. Габдулланың угыллары: Мөхәммәдрәхим, Хөсәен, Сафиулла. Мөхәммәдрәхим углы Мөхәммәддин сугышта үлгән. Хөсәен угыллары: Сөләйман, Хәсәншәех, Әбүталиб. Сафиулла углы Сәгыйт.

3. Габделгазиз угыллары Кәрамулла һәм Габделҗәлил. Кәрамулла угыллары Миргадийан һәм Хәсән. Габделҗәлил угыллары Җәмил һәм Мәгъсүм.

4. Габдерәкыйб углы Габделмәҗит, Габделмәҗит углы Газиз.

5. Хәмидулла (Хәмкәй) угыллары: Хәлиулла, Гарифулла, Зәйнулла, Нәбиулла, Гәрәйша. Гарифулланың углы Нигъмәтулла, Нигъмәтулланың угыллары Галимҗан һәм Мәгариф. Гәрәйша угыллары: Мөсәит, Фәнис, Миршәриф.

6. Солтангәрәй углы Арслангали. Арслангали угыллары: Шаһгали (1900-39), Сәетгали, Миңнегали, Галиразый.

Н.М.: Укытучы Нугайбәков Шаһгали абыйны 1937 елны “халык дошманы” дип гаепләп кулга алалар, 1939 елны Бөгелмә төрмәсендә үлә. Аның улы Рафаел, кызлары Ганҗә (1925) һәм Вилена (1938). Ганҗә апаның уллары Сәлим һәм Галим Абдуллаевлар. Юстиция генералы Галим Убайдович (1951-1997) Тымытык - Казан юлында автоһаләкәттә вафат булды. Икенче елны Мәскәүдән Әнисе янына кунакка кайткач  Сәлим (1948-1998) Ык елгасына батып үлде.

Галиразый уллары **Ардинат** һәм Айрат **Нугайбәков**лар Әлмәттә яшиләр. Ардинат Галиевич һәм аның улы Ренат – “Татнефть” берләшмәсендә югары урыннарда эшләүче атаклы нефтчеләр. Ардинат әфәнде  зур иганәче: Тымытык тарихи җәдитчеләр мәдрәсәсен мәчет итеп торгызып куйды; Чалпы аулы иске зияратында Нугайбәк бабабыз, аның уллары һәм туганнары каберлеген төзәтеп истәлекле һәйкәл-некрополь булдырды; Әлмәт районы Кичү-чат аулында Ризаэтдин Фәхретдин музеен нигезләде һ. б. Айрат Галиевич Нугайбәков - танылган табиб (врач). Гөлшат Ардинатовна Нугайбәкова Казан мәдәни-агарту үзәгендә татар хатын-кызлары киемнәре һәм бизәнү әйберләре буенча зур белгеч. Лекцияләр укый, күргәзмәләр оештыра. Тарихи бизәнү әйберләре буенча үзенең зур шәхси коллекциясе бар.

Габделваһаб (1779-1844) Нугайбәковтан таралган балалар. Н.М.: Нурлыбанат әби, профессор Заһидулла абый һ. б.

Габделваһаб сотник булган, аның угыллары (өч  хатыннан): 1- Галиулла (1813), 2 - Әхмәтбай, 3 - Мөхәммәдвәли (1805), 4 - Габделсаттар, 5 - Әхмәтҗан, 6 - Миңнехан,
7 - Хакайгәрәй, 8 - Әхмәтвәли, 9 - Хисбулла.
Кызлары: Фәхриҗиһан (1823), Бибимәгубҗиһан (1817), Бибинурҗиһан, Бибиҗиһан.

1.М.М.: Галиулла угыллары: Кашшафетдин, Хабибулла, Шәрафетдин, Шәрифулла, Халилулла, Мөслахетдин.

Кашшафетдин угыллары Мирдаһит (-заһит) һәм Әкмәлетдин, аның ике углы бар.

Хәбибулла угыллары Дарифулла (Зариф-)  - аның углы җук һәм Хәмидулла мелла, аның угыллары - Гарби һәм Хәнәфи. Шәрафетдин углы Мөхәммәдшакир армиядә үлде, икенче углы - Галиулла, аның угылы Мөслахетдин.

Н.М.: Мөслахетдин  угыллары: (өлкән) Гыймадетдин 1936 елда Бәйрәкә нефтебазасында янып үлгән. Хәйретдин, Афзалетдин, Мөхәммәдсабир сугышта һәлак булганнар. Хәйретдин фронтта безнең булачак бабай Миргарифан белән бергә була, атака башлангач Миргарифан аны үз янына ышыгырак урынга чакыра. Хәйретдин: “Ярар, абзый,”- дип җавап бирә, ләкин килергә өлгерми, тавышы да ишетелми башлый. Шул ук көнне (09.12.1941 ел)

Миргарифан бабай да каты яралана.
Афзалетдин Мириханның кыз-оныгы Разифага өйләнгән була, аларның углы (кече) Гыймадетдин (-зетдин,1937-), аның углы Илшат (1960) Азнакайда яши.
М.М.: Шәрифулла угыллары: Габделмөсавир (ир баласы җук) һәм Габделгаффар. Габделгаффар угыллары Габделбасыйр һәм Габделгани, аларның уллары бар.

Н.М.: Хәлилулла уллары - Талибулла, (өлкән) Заһидулла (1914 елгы Герман сгышында үлгән), Шафигулла, Самигулла; кызлары - Маһиасма, Маһиҗамал, Гайнелхәят, Нурлыбанат (безнең Әби).

**Нурлыбанат** (1903-1995) бу язмаларның төп авторы Миргарифан Мирихан улының хәләл җефете.
Гайнелхаят әби Азнакай районы Яшләү аулында гомер итте, кайбер балалары Төрекмәнстанда яши.
Маһиасманың кызы Өммемаһни - аның уллары Ильяс, Мирзаян. Ильяс Мортазин (1935-2000) -галим, Казанда фәнни институтта эшләде.

Талибулланың сигез баласы булган, шулардан дүрт угылы: Гарафлилла (1924-1943) сугышта үлгән, Такиулла (1926-1996), (кече) **Заһидулла** (1929 - 2011), Рәфәт (1936).

Загид Талибович **Галиуллин,** Мәскәү - магистраль газүткәргеч трубалар хисаплау буенча халыкара күренекле галим, күп еллар ВНИИгаз институтының җитәкчесе булып эшләде, фән докторы, профессор. Улы Рөстәм (1963)

хатыны Кадрия белән (Ульяннан) Мәскәүдә яшәп яталар.
М.М.: Даһидулла (Урсай, өлкән Заһидулла) углы Хәмидулланың угыллары Асуат һәм Рәис. Асуатның углы Айрат, Рәиснең углы Рәфис. Даһидулла углы Газизулланың ике углы бар. Шафигулла углы Сәгадәт (Яңа Урсай), аның углы Фәрәгат армиядә үлде, тагын ике углы бар. Самигулла углы Гарафулла сугышта үлде.

2. Әхмәтбай углы Мирсәйет 1916 елда Чалпы юлында буранда үлде. Мирсәйетнең углы Габдрахман да 1911 елда Кәрпи белән Урсай арасында буранда улгән булган.

3. Мөхәммәдвәли угыллары: Габделхәким, Мөхәммәддакир, Габделгани, Җиһансөяр (-сүвәр). Габделхәким угыллары Габдерәүф, Габделһади. Мөхәммәддакир угыллары: Гарифҗан, Мөхәммәдхафиз, Хөсәен. Гарифҗан һәм Хөсәен телсез булганнар. Мөхәммәтхафиз угыллары Салихҗан һәм Фатих. Габделгани угыллары Ашрәфҗан һәм Салихҗан.

4. Габделсаттар угыллары: Габделгали, Габделгаффар, Габделҗаппар, Галиулла, Хөснулла.
Габделгали угыллары Мөхәммәтдакир һәм Габделгани.
Мөхәммәддакир углы Мөхәммәдгариф. Габделгани угыллары: Габдулла, Габдулхак, Габдрахман (“Сәнәкчеләр фетнәсе”-ндә үлгән), Миңнегалим.
Н.М.: Миңнегалим улы Миңзаһит Ганиев - Галия апа Миргарифан кызының ире**, Зәйтүнәнең** (1954, Казан) әтисе.
М.М.: Габделгаффар углы Мөхәммәтшакир.

Мөхәммәдшакир угыллары: Миргасим, Миргали, Мөхәммәдшәех, Мөхәммәдтаиб, Мөхәммәдгариф. Габделҗаппарның углы җук. Хөснулла улы Хәмидулла. Н.М.: Габделсаттарның кызы **Хәерниса** - бу язмаларның төп авторы **Миргарифанның Әнисе**. Икенче кызы **Хәдичә** абыстай - Кәкре елга аулыннан Сабир бай хатыны. Заманында **Магнитогорск**ига сөрелгәннәр, 1960-нчы елларда өч кызы белән Урсайга кунакка кайтып йөрделәр.

5. М.М.:Әхмәтҗан углы Әхмәтсәгыйт, Әхмәтсәгыйт углы Гарифҗан, Гарифҗан углы Салихҗан.
6. Миңнехан угыллары: Габдеррәкыйб, Мөхәммәдҗан, Әхмәтхан.
7. Хакайгәрәй углы Гыйлаҗетдин, Гыйлаҗетдин угыллары Зыятдин һәм Миргаяз.
8. Әхмәтвәли углы Әхмәтшәриф, Әхмәтшәриф углы Әхмәтзәки.
9. Хисбулла угыллары Хөснулла, Вәлиулла, Нәбиулла. Хөснулла угыллары: Габидулла, Шәйдулла, Лотфулла, Газизулла. Габидулла угыллары Мәгъсум һәм Мөхтәсим. Шәйдулла һәм Лотфулланың угыллары күп. Вәли угыллары Әбүләис Һәм Миңнехан. Нәбиулла углы Сәмигулла.

Гомүмән, Габделваһаб нәселеннән:
Нурлыбанат әби - Миргарифан бабайның хатыны, Хәерниса әби - Миргарифан бабайның әнисе, профессор Заһидулла Галиуллин, Миңзаһит абый - Зәйтүнәнең (1954) әтисе, Хәдичә абыстай гаиләсе - безнең Магниттагы кардәшләр.

Сәлтәш Нугайбәковтан таралган балалар.
Н.М.: Сәлтәш - Әхмәтхан - Мирихан (1853-1914).
Филолог-галим Гимад Нугайбәк (1881-1943).

Сәлтәш бабабыз 1816 елгы документларда казак гаскәренең 10 аулны үз эченә алган юрт старшинасы буларак күрсәтелә. Аның ике хатыны Сәхипҗамал һәм Хөснибанудан (1786) угыллары: 1 – Акчуак (1803-), 2 – Шаһимөхәммәд (1810-), 3 – Шаһиморда (-морза, 1807-), 4 - Гәрәйша, 5 – Җиһангир, 6 - Әхмәтхан мулла (1828-).
Кызлары: Бибигильмениса (1799), Шөкербану (1801), Шәрифә (1808), Латифа (1810); Гафифә (1810), Бибифәсхиҗиһан (1815).

Сәлтәш бабай (1766-1834) Чалпы иске зияратында Әтисе Нугайбәк (1736-1802) һәм башка туганнары янәшәсендә җирләнгән. Шунда ук беренче хатыны Сәхибҗамал Гомәр кызы (1771-1844) да гүр иясе булган.

1. Акчуак казак гаскәрендә хорунжий, юрт старшинасы (1850) булып хезмәт итә. Аның угыллары: Нуримөхәммәд, Габдулла - углы җук, Габделгани. Нуримөхәммәд угыллары Хаҗимөхәммәд һәм Шаһимәрдан. Габделгани углы Сәгыйр.

2. Шаһимөхәммәд угыллары: Мирхәйдәр, Миргали, Җиһангир, Мөхәмматҗан. Мирхәйдәр угыллары Нурмөхәммәд һәм Нургали. Миргали угыллары: Шавәли, Габдрахман, Мөхәммәдҗан, Мөхәммәдсафа.

3. Шаһиморда (-морза) казак гаскәрендә урядник (1850) булып хезмәт итә. Аның угыллары Әбүбәкер һәм Шәйхелислам. Әбүбәкер угыллары: Мөхәммәдгата, Сафа, Вәли. Шәйхелислам углы Әхмәтлатыйф, Әхмәтлатыф углы Мөхәммәддакир (-закир).

4. Гәрәйша углы Хөрмәкәй, аның угыллары Шаһгасыйм һәм Гыймаделислам – Ватан сугышында үлде, аның угыллары Фоат, Баис, Баисның углы Марат. Шаһгасыйм угыллары: Габдрахман - Ватан сугышында үлде, Мәрданша, Йәһүдә (Яһүдә). Мәрдәнша улы Илһам.

5. Җиһангир угыллары: Мөхәммәдҗан, Мөхәммәдшафигъ, Мөхәммәдвәли. Мөхәммәтҗан угыллары: Гыйладетдин - - Герман сугышында үлгән, Мөхәммәдхан, БорҺан, Аксак Әхмәтхан, Салихҗан. Мөхәммәдхан угыллары Галимҗан һәм Шәрифҗан.
Н.М.: Шәрифҗан улы Гимадетдин Нугайбәков -

– татар теле галиме-филолог **Гимад Нугайбәк** (1881, Саратов өлкәсе -1943, Казан). 1893 елдан Казанда “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә укыган һәм Галимҗан Баруди вакытында шул ук мәдрәсәдә укыткан. ”Башлангыч” (1910), “Грамматика (татар теле)” (1911), “Сагынмалык” (1912) дигән  фәнни китаплар авторы. 1912 елдан “Кояш” газетында мәкаләләр белән чыгыш ясый. Гимад Нугайбәк китаплары һәм мәкаләләре Габдулла Тукай шәһесен һәм иҗатын формалушга тәэсир ясаган. Г. Нугайбәк 1917 елдан

Кызыл байрак” газеты белән хезмәттәшлек итә башлый, 1925-26 елларда татар телен латин алфавитына күчерү хәрәкәтенә кушыла. 1926 елда үзенең тәкъдимнәре белән Бөтенсоюз тюркологлар съездында катнаша. Россиянең эчке мөселман Комиссариатында эшли. (8, с. 396).

5. Җиһангир угыллары... (дәвамы): Борһан, аның углы Мифтахетдин, аның угыллары Фәнис һәм Айрат. Мөхәммәдшафигъ угыллары: Мөхәммәдсабир, Аксак Салих, Фәтих. Мөхәммәдвәли угыллары: Садыйк, Мөхәммәдгата, Мөхәммәт.

6**. Әхмәтхан** Сәлтәш углы
(1828-) - Чалпының указлы мулласы, беренче хатыны Фәхрелбанат Зәйнетдин кызыннан угыллары: Мөһәммәдхан мулла (1858-), Мөслахетдин ахун (1851), Миһрихан (Мирихан) мулла (1853-); икенче хатыннан - Касимхан, Мийәссәр.

Мөхәммәдхан  Кышкар мәдрәсәсен тәмамлап кайткач Чалпының бер мәхәлләсендә мулла була. Мөхәммәдхан угыллары: Мөхәммәдфарса, Фаиз, Рәшит. Мөхәммәдфарса улы Рәфәт, аның улы Җәүдәт. Фарса бабай кызы, Чалпыда озак еллар укытучы булып эшләгән Назнин Нугайбәкова Чалпы аулы турында берничә китап язган Сәлах Шәриповның тормыш иптәше.

Мөслахетдин ахун (1851-1927) Минзәлә өязендә һәм Илецк шәһәрендә эшли. 1913 елда патша тарафыннан Алтын медаль белән бүләкләнә. (8, с. 391).
М.М.: Аның угыллары: Габделхай, Габделбәр, Габделразак (-вәдүт?) Нугайбәковлар гражданнар сугышы вакытында Ташкентка китәләр. Габделбәр уллары Рафаэль һәм Алик Ташкентта яшиләр, Рафаэль хәрби уку йортында (воен. училищеда) укыта.

Касимхан (-1903) угыллары Шакирҗан һәм Салихҗан. Салихҗан кызы - телсез Майтабан (Маһитабын?).

Мийәссәр (1883-1958) мелла углы Мирмәгъсүм.

**Мирихан** Әхмәтхан улы Нугайбәков
(1853-1914) - сотник (берничә аулга администрация башлыгы), соңрак Урсай аулында мулла.
Н.М.: 1864 елда кантон-казак системасы бетерелгәч сотниклар МВД структурасына күчерелә, ә указлы муллалар инде күптән МВД идарасе астында булалар.
Мирихан 1872 елда бер төркем кардәшләре белән Чалпыдан Урсайга күчә.

Мирихан бабайдан (1853-1914) таралган балалар.

Мирихан угылларылары: Сәлахетдин, Габдулла, Миргарифан (1903-77), кызы Бибиасма. Мириханның бердәнбер хәләл җефете - Хәерниса әбиебез.
Сәлахетдин 1907 елны яшүсмер вакытында чирләп үлгән.
Габдулла (1898-1917) - өйләнмәгән яшь егет Герман сугышында вафат була.
Н.М.: Бибиасманың кызлары Мөнәвәрә һәм Разифа.
Мөнәвәрәнең балалары Мирхатип, Әдинә Лениногорскида (ТР) яшәделәр. Әдинә кызы Ирина Мәскәүдә яши.
Разифаның улы Гыйматдин абый (Гыймай, Гымазетдин), аның улы Илшат Азнакайда яши.

Нугайбәк шәҗәрәсендә Мирихан тармагы (ирләр):
Нугайбәк(1736-1802) - Сәлтәш (1761-1834) – Әхмәтхан(1786-) - Мирихан (1853-1914) - **Миргарифан** (1903-1977) - ...
Нугайбәков Мириханның улы Миргарифан 1937 (!) елдан Мириханов фамилиясен йөртә башлый.

М.М.: Миргарифан угыллары: Мирхафидан (1925-), Мөҗәһидан (1927-), Бәгис (1930-), Легендар (1939-), Фәнис (1945-).

Н.М.: 1-нче улы **Мирхафидан** (-физан) Мириханов (1925-) турында Миргарифан бабай язмасы алдагы бүлектә Ватан сугышы чоры белән бәйләп бирелә. Чөнки, 18 яшьлек Мирхафизанга язмыш башка гомер бирмәгән.

М.М.: 2-нче улым **Мөҗәһидән** Мириханов (1927-)
1944 елны (17 яше тулмаган килеш)  армиягә алынып, сугыштан соң яше җитеп хезмәттә калып, 1951 елда гына, җиде елдан артык гомер узгач, туган якка әйләнеп кайтты. Армиядә күп төрле курсларда укып, практикалар үтеп профессияләр алганлыктан Тымытык МыТыеСына (МТС - машино-тракторная станциягә) эшкә урнашты. Бер ел эшләгәч Министерство аны укырга җибәрде. Йошкар -Алада укып, инжинир булып кайтып МТС-та 20 елга якын эшләде. Хәдерге вакытта (1975) Тымытык мәктәбендә механизаторлык буенча укыта.

3-нче улым **Бәгис** Мириханов (1929-)
“Тельман” колхозында (Урсай) күп еллар механик һәм комплекс-бригадир булып эшли.
Н.М.: Бәгис абый бик яратып Тымытык кызы Мөзәббирәгә өйләнде. Берзаман, студент вакытта Казанда тулай торакта ятам, ни күрәм - Бәгис абый буш зур чумадан күтәреп килеп керде. Мөзәббирә апаң авыр хәлдә, берни ашамый, лимон сорый, ди бу. Чаптык базарга, чумаданны тутырып лимон алдык. Бәгис абый шундук Урсайга юл алды (400 км). Әммә лимон ярдәм итмәгән. Мөзәббирә апа авыз итеп кенә караган да, берсеннән берсе кече дүрт кызын калдырып, яшь килеш яман шеш (рак) авыруыннан дөнья куйды. Бәгис абыйның кызлары Мөнирә, Резеда, Раушания, Ләйсән без Урсайга килеп Әби-Бабайның капка төбенә туктауга яз-көз, карлы-бозлы вакытларда, өс киемсез, яланаяк үзләренең өйләреннән йөгереп килеп җитәләр иде.

Бүгенге көннәрдә Мөнирә ире Илдар белән Кукмара районы Вахит аулында яшиләр. Уллары Рамил Казанда.

М.М.: 4-нче улым **Легендар** Мириханов (1939-) Бөгелмәдә механидаторлар курсында укып Тымытык МыТыеСына кайтып эшкә урнашты. 1958 елда Кызыл армиягә алынды, Томск шәһәрендә хезмәт итте, шунда ук “Динамо” спорт җәмгыятендә штанга күтәрү спорты белән бик уңышлы шөгыльлөнде.
Н.М.: Мин (Назиф) Урсайда яшьләрнең берничә атка төялеп гармун уйнап җырлый-җырлый Легендар абыйны армиягә озату бәйрәмендә уралып йөрдем. Без Назил белән Легендар абыйга армиягә хатлар язып тордык. Мин хәзер дә ярата торган “сгущённое молоко”-ны беренче тапкыр Легендар абый армиядән алып кайткан күчтәнәчәр арасында авыз иттем.
М.М.: Легендар улым армиядән Чистай шәһәренә кайтып авыл хуҗалыгы техникумына укырга керде һәм штанга буенча тренер булып эшләде, Чистай штангычыларын алдынгы урыннарга чыгарды. Укуын тәмамлагач Азнакайга кайтып райкумда эшләде, читтән торып ничәдер еллар Мәскәүдә (югары) партшколада укыды, имтихан биреп диблум (диплом) алып кайтты. Аннан Легендарны райиспалкумга җаваплы эшкә билгеләделәр һәм озак та тормый “Вахитов” сафхузында (совхозында) директор эшен тапшырдылар. Хәдерге көндә шул сафхузда эшли.
Н.М.: Легендар абый - яшь чагында сабан туйлары батыры,

армиядән авыр атлетика буенча спорт мастеры булып кайтты. Ул эшләгәндә Азнакай районының Вахитов совхозы юка йонлы сарыклар үрчетү буенча “Руно” Берләшмәсе булып үсте. Аннан соң Легендар абый “Җәлилнефть” идарәсе һәм “Татнефтегазстрой” (Әлмәт) берләшмәсе агрофирмалары җитәкчесе, Әлмәт районы Мәмәт совхозы директоры булып эшләде. Мәмәт аулында Легендар абый истәлегенә аталган Мириханов урамы бар, ул “Почёт Билгесе” ордены кавалеры.

Легендар абый 1989 елны 50 яшендә вафат булды. Аны соңгы юлга озатуда беренче адымнарны миңа башкарырга туры килде. Чөнки Легендар абый санаторийдан кайтышлый Мәскәүдә дөнья куйды. Хастаханәдән алып Әлмәттән махсус авиарейс чакыртып Легендар абыйны туган якка озаттым. “Быково” аэропортына каршыларга килүчеләр арасында Фәнис абый да бар иде, ул кайгылы эстафетаны миннән кабул иттеп алды.

Легендар абыйның кызлары гаиләләре белән Флёра (1963) Мәскәүдә, Гөлнара (1966) Әлмәттә яшиләр.

М.М.: 5-нче улым **Фәнис** Мириханов (1945)

11 классны Тымытыкта бетереп Казан химия-технология институтында алты ел укып, Пермь шәһәрендә хәрби заводта инжинир булып эшләде. Хәдерге көндә шул ук заводта цех начальнигы.

Н.М.: 1969 елны институтка керергә мин (Назиф) Казанга Фәнис абыйларга Оренбург трактына килеп төштем. Фәнис

абый шунда минем “Карамуллин кызы” белән йөргәнне белде, почта белән Розаның хатларын ул алып керә иде. Фәнис абый миңа Чокурдахтан (Якутиядән) бик шәп свитер һәм җылы эчле плащ алып кайтты. Ул анда КХТИ-дә диплом яклар алдыннан иптәшләре белән шабашкага киткән иде. Хәдерге көндә Фәнис абый тормыш иптәше Розалия белән, уллары Илгизәр гаиләсе белән Казанда Салмачы бистәсендә  һәркем үз йортында яшәп яталар.
Миргарифан бабай белән Нурлыбанат әбинең дүрт кызлары булган: Бәдерлехәят (1920-2009), Икълимә (1923) -  яшь бала вакытында үлгән, Галия (1933- ), Әминә (1936-).

М.М.: Өч кызыбызның өлкәне – **Бәдерлехәят**
Мигарифан кызы, Мөслим районы Мәллә-тамак аулында кырчылык һәм бакчачылык бригадиры булып эшләде. Ире Гыйлаҗетдин 24 ел тракторда эшләп (урманда агач тартырганда бүрәнә астында калып) фаҗигале рәвештә вафат булды, өч кызлары ятим калды: Әнисә (1940), Мәдинә (1946), Мөнәвәрә (1950). Ике олы кызлары мидицина буенча укып икесе ике аулда эшлиләр. Мөнәвәрә Казанда югары белемле теш врачына укып чыгып Актүбәдә эшли.
Н.М.: Мәдинә апа белән Мөнәвәрә бәләкәй чакларында безгә Тымытыкка кунакка киләләр иде. Мөнәвәрә МыТыеС эшчеләре алдында чирәмдә нәфис гимнастика күнегүләре белән чыгыш ясый иде.
Мәдинә апаның улы Рүзил Казанда яши.

М.М.: Икенче кызым **Галия** Мигарифан кызы (Татарстанның) Лениногорски шәһәрендә  яши, Письмянка

тимер юл станциясе складында эшли (1975).
Н.М.: Галия апа белән Миңзаһит абыйның кызлары Зәйтүнә (1954) ире Әхмәт (1951) белән Казанда яшиләр. Минзаһит абый да Нугайбәк нәселеннән.

М.М.: Өченче кызым **Әминә** Миргарифан кызы Башкортстанның Бакалы районы Боҗыр аулында мидицина буенча эшли. Ире, Шарифуллин Әнвәр - калхуз рәисе. Н.М.: Әминә апа белән Әнвәр абый балалры Әзһәр (1960), Румия (1963), Зилә (1967) Азнакайда яшиләр.

Н.М.: Тагын шәҗәрәгә әйләнеп кайтабыз. Миргарифан бабай өченче буын ир балаларны санап китә:
М.М.: Мөҗәһидән угыллары: Надиф, Надил (Назиф, Назил), Наил. Фәнис угыллары: Ринат (1967), Илгизәр (1987).
Н.М.: Илгизәрне үзем өстәп куйдым, Миргарифан бабай язганда ул әле тумаган иде.

Мөҗәһидән - ... тармагын кыскача гына язып куям: Әтиебез Мөҗәһидән белән әниебез Мәфрүзәнең өч уллары арасында кызлары  Фәйрүзә (1958) бар. Фәйрүзә һәм аның кызы Миләүшә (1981) Казанда яшиләр.
Назил (1955) белән Фәһимәнең (1954) балалары: Рәйхан (1980), Зөлфия (1982), Азат (1883). Бик күп оныклары бар. Барысы да Чаллыда яшиләр.
Наилнең (1962) балалары: Марат (1982), Марсель (1985), Фәридә (1990), Мансур; Эмиль; Алинә, Әмирхан. Фәридә

ире блән Мәскәүдә яши, калганнары бырысы да Казанда.

Бүген исән-сау булган Мирихан нәселеннән булган кардәшләребез үз тармакларын, тормышларын бик матур итеп үзләре язарлар әле, дип уйлыйм.

Безне тәрбияләп үстерүдә Әниебез Мәфрүзәнең роле бик зур булды. Ул безгә, соңрак оныкларына бөтен гомерен багышлады. Улларымны инженер итәм, дигән теләген дә бик эзлекле рәвештә тормышка ашырды. Минем күңелемә аның: “Авыз-борының кан булса да кеше алдында төкермә”, - дигән сүзе тормыш кагыйдәсе булып кереп калды. Димәк, зарланма, авырлыкларны җиңеп алга бар, максатларыңа ирешь!
Ильнур улым теләге буенча “Нәсел. Заман”-ның татарчасын яза башлагач Әнинең васияте искә төште. 1999 елда мин Миргарифан бабай  язмаларына нигезләнгән рус телендәге “Нәсел-Род” кулъязма китабымны Әти-Әнигә кайтарып биргәч алар бик әсәрләнеп укыдылар, китапны ошаттылар. Әммә Әни фикер алышканда әйтеп куйды: “Улым, син бу китапның татарчасын да яз инде”, - дип. Менә 25 елдан соң булса да Әнинең васияте дә үтәлә.

Мириханов **Назиф Мөҗәһидән улы** (сәхифәләр).

1952 елда Урсайда Миргарифан бабай гаиләсендә туганмын. Миңа, беренче ул-оныгына, исемне Бабай 1943 елны сугышта хәбәрсез югалган улына алмашка Мирхафизан дип кушарга теләгән. Әммә, өйдәге хатын-кызлар риза булмаган, дәлилләре: Мирхафизан үзе кайтып керергә мөмкин әле, яшь баланың гомере булмас. Миргарифан бабай җаен тапкан бугай, Мирха-физан дигән исем гарәб хәрефләре кебек сулдан уңга укыганда Назиф-ахрим килеп чыга. Бу турыда Бабай белән сөйләшкән булмады, кызык итеп кенә язам, Миргарифан бабайның сере булып калсын. Ярый әле, исемнең Ахрим дигән кисәге миңа эләкмәгән. Совет заманында мондый гадәт татарларда күренә башлаган иде. Солтан дигән бер кеше малаена үз исемен кирегә укып Натлос дип исем кушкан.

Тымытыкта мәктәп елларыннан ук башланган беренче мәхәббәтебезне саклап 1973 елда Кәрамуллина Роза Газизулла кызы белән гаилә кордык. Никахны Миргарифан бабай укыды. 1974 елда туган кызыбыз Чулпанга да исемне Миргарифан бабай кушып өлгерде.
Роза миңа тормышымда рухландыручым, киңәшчем, зур ярдәмчем, һәм ныклы терәгем булды.
Әлмәттә (1974-1985 елларда) төзелештә мастердан башлап участок (23 яшьтән), СМУ (25 яшьтән), трест (28 яшьтән) җитәкчесе булып эшләдем һәм 33 яшьтә инде Мәскәүдә

Академиядә идем. Мин Розага хезмәт юлым буенча этиләребездән ким булмаячыгымны исбат итәргә тырыштым. Һәм, нишләптер, әтиләр үзләре дә миннән шуны көтәләр иде кебек.
СССР Халык хуҗалыгы Академиясен (АНХ при СМ СССР) тәмамлап (1985-87)  Мәскәүдә зур урыннарда эшләдем.
1999-2010 елларда Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы хокуклы вәкиле- Премьер-министр урынбасары булып тордым.
Бөтен уңышларымны мин Роза белән уртаклашам. Аңардан башка минем холкымдагы тискәре якларым өстенлек алып язмышымның сыйфаты түбәнрәк булыр иде.
Гомер буе бик бирелеп эшләдем һәм укыдым. Биш-алты дипломым һәм таныклыгым бар, шуларның икесе өстәмә югары белем алу турында. Институт һәм Академияне кызыл дипломга тәмамладым. Икътисад фәннәре буенча кандидатлык, политология буенча докторлык диссертацияләре якладым. Хәттә Германия һәм Америкада курслар үттем.
Хезмәт юлымны 70 яшькә кадәр дәвам иттем. Түгәрәкләп әйткәндә 40 ел гомерем октябрят –пионер –комсомол - коммунист рухында совет заманында үтсә, соңгы 30 елда капитализмны кайтардык.  Һәр җәмгыяви формациянең үз уңай һәм тискәре яклары була. Шәхсән яктан караганда начар-яхшы заманнар юк, безнең заман гына бар, дип әйтәләр, бу очракта. Кеше үзе яшәячәк заманны  сайлап ала алмый.

Хәзер безгә 70+, Роза белән икәү бер-беребезне карап әкрен генә яшәп ятабыз. Роза мине бала караган кебек карый, ЛДЦ (лечебно-даигностичексий центр)-га җитәкләшеп йөрибез.  Роза гадәт буенча хуҗалык мәшәкатьләрен, әз-мәз минем ярдәм белән, үзе алып бара. Җаваплы эшләрдә эшләгәндә ул мине өй эшләре белән борчымаска тырыша иде. Тормышның бу өлкән яштәге баскычында да матур яшәп була икән.

Кызыбыз Чулпанның (1974) ике улы бар: Тимур (2000) һәм Сәлим (2001). Киявебез Арслан Намык Камил углы (1971-2018) 47 яшендә яман шеш авыруыннан вафат булды. Чулпан белән танышканда Намык Төркиядән Мәскәүгә Төзелеш институтына укырга килгән студент егет иде. Чулпан да шул институтта укыды, кызыл диплом белән тәмамлады. Чулпанның уллары Тимур Мәскәүдә, Казанда, ә Сәлим Испаниядә профессиональ белем алдыар. Хәзер үз тормыш юлларын корырга тырышып йөриләр.

Улыбыз Ильнурның (1979) тормыш иптәше - (Невретдинова) Ләйлә Вәлид кызы, Мәскәүдә туып үскән, югары белемле музыкант - скрипкачы. Аларның дүрт балалары бар: Камиль (2000), Алия (2005 ), Айгөл (2008), Җәмилә (2016). Ильнур озак еллар Мәскәүдә Төркия банкында уңышлы гына эшләде, аннан бизнеска күчте, бик күп телләр белә. Лингвистика, этнология, төркичелек, тарих белән кызыксына.

Тормыш дәвам итә, 2024.

Миргарифан бабай (1903-1977) үз тормышы турында.

М.М.: Әтием Мирихан (1853-1914), тынгысызлык туганлыктан, 1872 елда бер төркем башкортлар белән Чалпыдан  Урсайга күчкән.
1877 елда җир бүлү башланган. Халык арасында кычкырыш күп булганлыктан, Урсай аулын куркыту өчен патша тарафыннан “убжурный” (обжорная) команда килгән. 250 солдат мәгәр дыян (зыян) салмасалар да унбиш көн торып киткәннәр.
Үзем, Мирихан углы Миргарифан 1903 елда Урсайда туганмын. Миңа белемне Әтием Мирихан мулла бирде. Рус теле һәм дөньяви фәннәр (математика, география, механика, физика) өйрәнү өчен күрше рус авылы Бадракта берничә ел чиркәү-приход школына укырга җибәрде.
Н.М.: Аул халкы: ”Мирихан мулла улын урыс итә икән”- дип сөйләгән. Без белгән чакларда да Миргарифан бабай Бадракка классташлары белән очрашуга чыгып югалгалый иде. Мириханның “прогрессив” кеше булуы тагын аның аулда беренче булып велосипед сатып алуында да күренә.
М.М.: 1905 елда беренче “рибалүтсия” (революция) кузгалган, п атша тарафыннан басылган. 1914 елны Германия Русиягә каршы сугыш ачты.
Н.М.: Миргарифан бабайга 11 яшь булганда 1914 елны 61 яшендә Әтисе Мирихан үлеп китә. Бәләкәй малай авыру Әнисе белән генә кала. Тормыш алып бару  өчен Миргарифан үзлегеннән бик күп һөнәрләр өйрәнә башлый:

трантас, читән, каз оялары үрү; башта кул белән, анан машинкада кием тегү; мич чыгару; бура бурау һәм агач эшләре; калай-тимер эшләре; балык тотарга ятмә бәйләү, ау белән балык тоту. Шул һөнәрләре белән дөнья көтә башлый.

М.М.: 1917 елның август аенда Миндәләдән (Минзәләдән) 50 пар олау (повозка) белән (Вакытлы хөкүмәтнең) 100 солдаты килеп Тымытык вулысындагы (волостендагы) патша сүрәтен һәм ышкафтагы (шкаф) язуларны, күзгә күренгән дәлилләрне (бу очракта, патша чорына кагылышлы әйберләрне), нинди булуына карамастан, урамга алып чыгып өеп яндырдылар.
Ул вакытта вулыс старшинасы Урсай авылыннан Камали Хисаметдин углы була. (Н.М.: Үз язмаларының башында Миргарифан бабай  нәсел шәҗәрәсен беренче тапкыр Камалетдин Хисамиевтан күчереп язганын әйтә.) Вулыс секретаре булып Башкорт ягы Корчай авылыннан керәшен Бөкре Гришка Антонов эшли.
Камали ага бер кеше белән сүләшеп (Дәүләтшин Имамны) Тымытыктан кайтышлый  үтерелүдә гаепләнә. Вакытлы хөкүмәт солатлары боларны кулга алып Миндәлә төрмәсенә илтеп ябалар. Камали ага халык сайлап куйган старшина булганлыктан, ун көннән котылдырып кайтаралар. Аннан соң Тымытык вулысына Урсай авылыннан рибалүтсианир (революционер) Шәмсетдин углы Сәхи аганы испалкумга (исполкомга) старшина итеп куялар. Секретарлыкны шул ук Бөкре Гришка алып бара.

1917 елның 25-нче  үктәберендә тагын рибәлүтсия ачылды. 1918 елда бик каты Гражданнар сугышы башланды. Чехлар, аклар, Колчак һәм Деникин Кызыл гвардиягә каршы бик зур сугыш ачтылар.

Нурми һәм Мәрьям язмышы.

Урсай авылыннан Нәҗметдин углы Нурмөхәммәд (Нурми) дабравулес (доброволец) булып Кызыл армиягә китте. 1918 елның 29 февралендә Акай Күле дигән рус авылыннан йөз олаулап аклар армиясе Урсай авылы башына килеп тупланганнар. Алардан берәр сәгать алдарак биш атлы җайдак (верховой солдатлар) килеп, без, урамда уйнап йөргән малайлардан сораштылар: бу авылда кызыллар юкмы, дип. Без, белмибез, дидек. Шуннан соң җайдаклар авылның югары башына чаптылар. Озак та үтми мылтык аткан тавышлар ишетелде. Тымытык ягыннан бер кәшүфкәгә (кошевка - махсус ат чанасына) берничә кызылармис (-армеец) утырып  киләләр икән. Аларның берсе безнең Нурми абзый булган. Аларның Урсайдан азык-төлек алырга исәпләре булган. Теге җайдаклар  шуларны кулга алып Урсайга китергәннәр. Акларга ярдәм итүче Миһранов Сабирҗан бик тизлек белән минем атны җиктереп олауга алып китте. Югары очка барсак, ни күзгә күренә: Ильяс мулла өйе янында урамда дүрт кеше күлмәк-ыштан белән салкын карда басып торалар. Аларны ак гвардиячеләр сырып алганнар, кулларында кылычлары ялтырый. Кулга алынганнарның берсе - рус кешесе: Сез безгә тимәгез, барыбер Кызыл армия кулына төшәсез, дип

әйткән һәм бирелмәскә тырышкан. Шул минутта аны кылыч белән чапкаладылар. Ильяс мулланың улы Нурлыгаян ул кызыл  армияченең калдыкларын тирес чанасына көрәк белән тутырып Ык күпере башына илтеп аударып кайтты. Калган дүрт әсирне (пленныйларны) камчы белән бик нык тукмап хәлдән тайганнан соң, ике җигүле олау килеп бук түгә торган плитүнкәгә (плетёнкага) салып өстен торбыша (брезент япма) белән каплап ике аклар солдаты ыштабка (штабка) дип Акай Күленә алып киттеләр. Анда аларны шәрә килеш кыйнап салкын таш амбарга җабып куйдылар. 24 февральдә шул ук олау белән ул әсирләрне кире Урсайга алып кайтып бераз шаулаштылар да, Шаранга алып барабыз дип, Урсайның хәдерге дуңгыз фермасы тирәсендә чанадан төшереп кылыч белән турадылар. Күп кенә кеше олауда идек, барысын да күреп тордык.
Нурми агайның хатыны Мәрьям апа Бөгелмә ягыннан мулла кызы иде. Аны егермеләп аклар солдаты Әбүбәкер карт өендә тәүлек буе җафаладылар. Ул вакытта аул сәвите персидәтеле Газизуллин Сафиулла ага, серетаре Мөхәммәдгата Әбүбәкер углы иде. Солдатлар йокыга киткәч Гата агай Мәрьям апаны  ат белән Бадракка җулсыз (юлсыз) җирдән илтеп кайта.
25 февральдә аклар килгән юлларыннан тизлек белән качтылар. Ул вакыт Тымытыкка Кызыл армия килеп тулган була. 26 февральдә Урсайга да бик күп кызыл гвардиячеләр килде. Бөтен аул халкын олауга җиктереп алып чыктылар. Авыл сәвите бик тизлектә кабер казып биш кызылармисне,

күпер башына чыгарып түккәнен дә, бер кабергә күмделәр. Совет законы утыргач кабер өстенә һәйкәл куелды, Нурми шәһит - халык бәхете өчен һаләк булучы кабере, дип. Халык телендә “Нурми кабере” дип атала. Калган дүрт армиеснең кайсы яктан икәнлеге билгесез калды.
Һаләк булучыларны җирләгән көнне ук Нурминең хатыны Мәрьям апа кайтып ирекле рәвештә, ире өчен үч алырга Кызыл армия сафларына басты. Кызыл гвардиячеләр Урсай һәм Тымытыкта бер атналап тордылар, халыкның атларын җиктереп армия эшенә җәлеп иттеләр.

Н.М.: Мигарифан малай - хәрби олаучы (обозник).
М.М.: Мине,14 яшлек малайны, сәвит челиннары Ганиев Әшрәфҗан, Могътәсим углы Әхмәтҗан агалар атымны җиктереп олауга чыгардылар. Әнкәй – Хәерниса карчык елап калды. 5 март көнне кызыллар белән Тымытыкка киттек, аннан Сукаеш ягына чаптык. Аклар куа килә икән. Сәпәй урманында бугай тупландык. Тымытык ягыннан аклар сипкә тезелеп (цепью) киләләр, кара -каршы атышу булды. Шуннан соң кызыллар Сәпәй аулына чигенделәр, дүрт солдат яраланган булган. Кызыллар арасында Бадрак авылыннан минем таныш керәшен Фидер (Федор) Сизов ике углы белән бар иде. Алар кулларына корал алып Кызыл армиягә дабравулес булып язылганнар. “Мигарифан, син бездән калма, калсаң аклар атыңны алырлар, үзеңне үтерерләр,”- дип, мине үзләре белән Кәкре елга авылы аркылы Якыдан Бөгелмәгә чаптырдылар. Бөтен Кызыл армия Бөгелмә янында тупланды, анда дүрт кич кундык.

Минем атыма тимер юл складыннан (Н.М.: Бабай “пакхауз”, дип язарга тырышкан) бик күп итеп киез итек төяделәр һәм брезент белән каплап бәйләделәр. Аннан соң Богырыслан юлыннан бер армиес белән утырып киттек. Атымны һәм үземне армиесләр бик тәрбияләделәр. Озак үтмәс, сезнең якка кире барырбыз, диләр. Сине олауга җибәргән кешене атарбыз дип мине җуаталар (юаталар). Шулай итеп, бер алга, бер артка йөри-йөри атналар үтте. Көннәр бик җүеш (юеш). Җөктә (йөктә) киез итек күп булгач, җүешен салам, корысын киям. Мине армиесләр бик җәлләделәр, бер куфайка (фуфайка), чалбар, яңа сары ботинкалар бирделәр. Мәләкәс, Мәләкәс (шәһәре) дип сөйләшеп барган юлдан, беркөн бик зур керәшен авылына кереп фатирга (квартирага) таралдылар. Минем атны фатир хуҗасына карарга куштылар. Үземне өйгә алып кереп тәрбияләделәр һәм малай ят-йокла , ял ит, диделәр. Мин йокладым. Бервакыт фатир хуҗасы уята, тор, атыңны кара , ди. Ачуланып ихатага чыксам, минем атым тугарылган килеш ялгыз гына ашанып йөри. Бер армиес тә, беркем дә юк, берүзем калганмын. Көн яктырды, шул вакыт өч ат менгән (атка атланган) кешеләр килеп керде. Малай, монда кызыллар бармы, дип миннән сорыйлар. Мин беркатлылыгым белән, бар, дидем. Фатир хуҗасы, керәшен: Бу малай кызылларның олаучысы, дип әйтүе булды, тегеләр: “Әх, шулаймыни”, - дип миңа ике тапкыр камчы белән сыдырдылар. Аннан мине аулның икенче башына алып чыгып киттеләр. Икесе чанага утырып, берсе

алдан ат менеп, бер зур йортка алып килделәр. Болар башкортлар булып чыкты, бик ныклап сораштылар.

Н.М.: Вакыты буенча, 1918 елның март ае, бу Зәки-хан Вәлидинең кызыллар белән дә, аклар белән дә тарткалашып йөргән Башкорт армиясе килеп чыга. Миргарифан бабай да үз язмаларында кызылларны керәшен авылыннан куып чыгарган бу кораллы кешеләрне аклар дип атамый. Шушы ук елны Совет хөкүмәте аклар белән көрәштә Башкорт армиясен үз ягына аудару өчен Зәки-хан белән сөйләшүләрдән соң Башкортстан Республикасы төзү турында карар кабул итә.

М.М.: Башкортлар шул сорау алган өйдә мине кунарга калдырдылар, сыйладылар, үзләренең атлары белән бергә минем атны да солыга (овёс) куштылар. Иртәгәсен миңа бер язу язып һәм ыштанпа (штамп) басып Бөгелмәгә кире ничек кайтырга өйрәттеләр. Ауллар аркылы үткәндә шул язуны күрсәтеп юл сораштым. Кайсы юлдан барырга өйрәтүчеләр бераз озата да баргаладылар. Бөгелмәгә кайткач шул ук итек төягән җиргә бардым, итекләрне бушаттылар. Бер төенчекне (ашъяулыкка төйнәлгән әйберләрне) үземнеке дигәч, сүләштеләр дә кире бирделәр. Үземә ипи, атка берзингә (брезентка) солы салдылар һәм Әлмәткә кайтырга өстәмә язу бирделәр. Бөгелмәдә бер руска кереп чәй эчтем, жәлләп акча да сорамады, Әлмәткә юл өйрәтте. Әлмәткә кайтып аул башлыгына кәгазләремне күрсәттем. Инде карлар эреп, кара җир чыгып, юллар бозылып чанада йөрмәс хәлгә җиткән, чанам да ватылып беткән иде.

Әлмәттә чананы ташлап, бернәрсәне дә калдырмаска тырышып әйберләремне ат өстенә төядем дә үзем атланып юлга чыктым. Аулдан аулга озатучы бирделәр: Урсалы башына, аннан Кәшер авылына, Якый аулына. Кәкре елгага кайтып бер кич кундым. Иртәгәсен Кәтемгә кайттым, тау башында ат өстенә пулемёт көйләгән армиесләр очрады. Алар мине туктатып, язуны карап, сорашып, Чалпы ягына кайтырга куштылар. Алар аклар булып чыкты.
Урсай басуына халык язгы сабан сөрүгә чыккан иде. Юлда мине туктатып, нихәл туган, сине үлгән дип сүләделәр, диделәр. Мин сөенеп үз ихатабызга кереп баскыч төбенә килеп аттан төштем. Инәй (Әни) берничә карчык чакырып чәй эчәләр икән. Мине күрү белән Әни килеп чыкты да баскычтан ушсыз (хушсыз, аңын югалтып) егылып төште. Ат камыт-ысбруйлары (хомут-сбруи) һәм йөге белән абдарга (абзарга) таба китте. Без Әни белән кочаклашып өйгә кердек. Апрель аеның 9-нчы көне иде, 1918 ел. Беренче булып аул сәвите челины Могтәсимов Икътисам абзый йөгереп килеп керде һәм атны бушатты, тугарды. Энем, сине үлгәндер дип уйлаштык, диде. Тиз арада  башка күршеләр дә керделәр. Атыңны да алып кайта алгансың, диделәр. Авылдан синең белән эләгеп киткәннәр, 14 кеше атларыннан язып (югалтып, алдырып) кайттылар, дип сүләделәр. Үзләре бик кыенлык белән, кача-кача, интегеп кайтканнар. Шулай итеп, мин, озын юлга чыгып киткән сугыш олаучысы бу афәттән котылдым.
Шул ук елны, 10-нчы майлардан башлап 20 көн тирәсе

Кызыл армиянең берничә дивизиясе безнең аул аша Башкорт  ягына узды. Без аларны һәркөн олау белән озата тордык. Кызыллар авылга дыян (зыян) салмады.
1918 елның көзендә аул сәвите кушуы буенча Арсланов Әхтәмгәрәй абзый белән икәү  Кызыл армиягә разбирска (продразвёрстка) буенча икмәк җыеп озаттык. Ике ел буена һәркөн 10-15 олау Бөгелмә либатырына (элеваторына) җибәрелде, Керенский акчасы белән поты 36 сумнан.
1919 елда Урсайдан Башкортстан ягына 100 хуҗалык (!) күчеп утырды. Урман асты чирәм җире яхшы уңыш биргән. Хәдер шунда Яңа Урсай аулы булып яшәп яталар.

1919 елның нояберендә (16 яшемдә) өйләндем.
Н.М.: Нугайбәк нәселленнән булган Урсай аулы старостасы Хәлилулланың кызы Нурлыбанатны сорарга Мигарифан егетнең әнисе Хәерниса абыстай үзе барган. (Хәерниса әби үзе дә Нугайбәк нәселеннән). Хәлил бай  1914 елда үлгән Мирихан мулланы бик ихтирам иткән һәм яшьләрнең кавышуына риза булган, никахка бүләк итеп сыер биргән. Нурлыбанат та Миргарифанны ошатып йөргән булган, еллар үткәч, бу турыда Нурлыбанат әбинең, без - оныклары, үзеннән сораган идек. Чөнки, димләп өйләнешкән кешеләр турында шаяртып-чынлап төрлечәрәк сөйлиләр бит.

М.М.: Шул ук елны Урсай авыл сәвитенә сайлау вакытында челин булып үттем һәм замприд (председатель урынбасары) итеп билгеләндем (16 яшемдә).
Гражданнар сугышында ахырда Кызыл армия җиңеп чыкты һәм совет законы утырды.

1921-22 елларда ил белән каты ачлык булды, күп халык эт, мәче һәм адәм (кеше) итләре ашап җан сакларга тырышты. Ачлыктан халык бик күп үлде.
Әммә, соңрак та ачлык илдән китмәде. Көне-төне эшли торган совет кешеләре, бигрәк тә балалар, 1931-33 һәм 1946-47 елларда да тамак туйдыра алмыйча ачлыктан интектеләр.
1924 елны (миңа 21 яшь) бик озак авырудан соң Инәй (Әни) - Хәерниса карчык дөнья куйды. Авыру вакытында аны бик әйбәтәп хәләл җефетем Нурлыбанат карады.

Колхозлашу еллары.
1927-32 елларда авыл сәвите депутаты булып тордым. Бер сыйныф (халыкны классларга бүлеп ярлы крестьяннар, пролетариат) ягында гына булу, калхузлашу, төрле каты кампанияләр бик авырлык белән барды. Шул елларда активлар (совет активистлары) надан булулары белән күп кенә игенчеләрне дөреслексез раскулачивать итттеләр (малларын, йортларын тартып алдылар), сөргенгә (ссылка) сөрделәр. Аңлата белмичә калхузга көчләп кертү аркасында ауллардан күп кеше таралды. Халык аңламау аркасында, калхузга керүдән куркып үз икмәген җиргә күмеп яшерде. Әвәл (башта) ул игенчеләрнең ат, сыер, сарыкларын көчләп җыеп калхуз (колхоз) малы итеп хисапладылар. Халыкка каты салым салып, түли алмаганнарны төрмәгә җибәрделәр.
Н.М.: Миргарифан бабай сәвит активисты буларак “кулаклар” тарафыннан төнлә тыкырыкта күсәк белән

тукмала, өч көн аңсыз ята, чак кына үлми кала. Әммә вулыс милициясенә хәбәр итми, гариза язмый. Чөнки тукмаучылар ул ихтирам иткән Урсай кешеләре, ерак булса да кардәшләре була.
М.М.: 1929 елда Тымытык камбинатында “Кызыл трактор” калхузы төзелде. Безнең аулдан 15-20 кеше Кәрпи һәм Урсай тегерманнәрен арендага алып бер ел (оешма итеп) тоттылар. Аннан соң Урсайда да калхуз төзелде: персидәтеле Мөлек Абдуллин, секретар Шәйхради (-рази) Габдуллин булды. 1930 елда (“25 меңче”) рабочий арасыннан Рахимуллин дигән завот эшчесе Урсайга китерелде. Ул бер ел калхуз персидәтеле булып эшләп китте. Мин дә шул елны калхузга кердем, мал-туарымны калхуз абзарына илтеп тапшырдым.
1931 елда үзем калхузда тимерчелек ачып, баш тимерче булып эшли башладым.
Н.М.: Миргарифан бабай күмәк эштә маллар карап, басуга йөрүгә караганда үз алдына аерым һөнәрчелек эшен кулай күргән. Калхузга тапшырылган ат-сыер белән аларның иске хуҗалары арасында драматик  хәлләр булгалап торган. Үзләренең элекке хуҗаларын колхоз фермасында күргәч маллар алар янына йөгереп килгәннәр. Хуҗалары да “үз” малларын ныграк караган, ашаткан, сыпыра-сыпыра сөйләшкәннәр. Маллар еш кына калхуз фермасыннан качып өйләренә кайтып китә торган булган.
М.М.: 1930-нчы елларда аерым тормыштан калхузга күчү ныклап башланды. Мәгәр халыкка бик зур  авырлык килде,

караңгыдан краңгыга кадәр каты эш булды. Хезмәт хакы бертөрле дә юк. Көне-төне, акча түлә, дип халыкны кысу булды. Төрле салымнар салып, налук (налог) - ит, сөт, йомырка, сарык йоны, сарык сөте җыйдылар. Ашарга ипи юк, сатып алырга акча да юк.
Н.М.: Ачлык куркынычы тугач Миргарифан кардәше Хәләф абзый Сәлахов белән Узбәкстанга китеп бер кышлакта дүрт айдан артык тимерчелектә бик нык эшләп, ярыйсы гына акча эшләп кайткан.

М.М.: Авырлыкларга карамастан мин хезмәтемне тырышып һәм яратып башкардым. 1936 елны Казанда стахановчылар (алдынгы эшчеләр һәм калхузчылар) слётында катнаштым. Татарстанның Обком секретаре Г.Г. Байчурин кулыннан Мактау грамотасы һәм бүләк алдым. Минем белән Казанга Мөҗәһидән улым да барды. Кремлдә Сөембикә манарасына мендек, ул ябык иде , анда хезмәт алдынгыларына гына менәргә рөхсәт иттеләр. Казаннан бик күп китаплар алып кайттым, Г.Тукай әсәрләре һәм тарих буенча. Тарихи китапларның (авторлары Газиз Гобәйдуллин һ.б.) күбесен 1937 елны милицияләр өйдән-өйгә җыеп йөреп алып чыгып киттеләр.

Бөек Ватан сугышы (1941-45).
1941 елның 22 июнендә Гитлер Германиясе Совет хөкүмәтенә каршы каты сугыш башлады. 1941 елның август аенда Кызыл армиягә алындым. Калинин фронтында сугышта катнаштым. 1941 елның 9 декаберендә ыранин (ранен) булдым.

Н.М.: Миргарифан бабай яраланган командирны аркасына салып, уң кулы белән кочаклап шуышып сугыш кырыннан чыкканда немецлар ягыннан автоматтан атканнар. Пулялар Бабайның кулының дүрт бармагын чәрдәкләгән, окопка барып җиткәнче командир инде үлгән була.

М.М.: 1942 елның 8 март көнне комиссия карары белән сроксыз ялга кайттым. Кайту белән калхузда завхуз (завхоз) булып эшли башладым. 1942 елның декаберендә яңадан сугышка алынып киттем, Украина ягына. Харьков, Купянскиларда күп кенә инвалитлар трафи (трофей) җыюда хезмәт иттек. Аннан соң фронт эчендә комиссиядә кул һәм эчем яралы булгач, 2-нче группа инвалит биреп кайтарып җибәрделәр. Безне армийский комиссия ыфтаруй (второй) рангы тикшерде.
1943 елның 6 маенда кайттым һәм авыл хуҗалыгы машиналарын төзәтү эшләрен алып бара башладым. Кичләрен, буш вакытта хезмәт хаксыз тире иләп күп кенә тун тегеп ваенкамат аша абарунага (оборонага) җибәреп яттым. 1943 елның 3 август көнендә ваенкамат (Тымытыкта) комиссиягә чакырып минем сугыштан алып кайткан документларны, үзебез саклыйбыз дип, кулдан алдылар да икенче көнне үк, 4 августа Казанга хәрби заводка җибәрделәр. Анда тегү һәм кием кисү эшендә яхшы гына эшләдем.
Бер өй эченнән үзем һәм ике улым **Ватан сугышында** булдык.

1925-нче елгы беренче **улым Мириханов Хафиз**ны
10-нчы классны Бөгелмәдә тәмамлап кайтып калхузда бригадир булып берничә ай эшләгәч ваенкаматка  палитрук итеп алдылар. (Ул мәктәптә укыганда актив, камсамул секретаре булып йөргән иде).  Ваенрук буларак Мирхафидан яшьләрне һәм хатын-кызларны армия хезмәтенә өйрәтә һәм укыта. **1943** елның февраль башында армия сафына **алына**.  Суздаль шәһәрендә алты ай командирлар курсында укый. Аннан соң сугышка керәләр һәм Мирхафидан ыранин (ранен) була, дәхи (алга таба) шул ук хәрби частьтән (18 яшендә) хәбәрсез югала.
Н.М.: Нурлыбанат әби белән Миргарифан бабай 1960-нчы елларга кадәр Мирхафизан абыйның кайтуын бик нык көттеләр: урам якка тәрәзәдән карый-карый, чәй әзерләгәндә Мирхафидан кайтып керсә, дип әзерләп һ.б. Баштарак хәрби архивлардан соратып язулар буенча төгәл хәбәр булмады. Мин үзем дә язып караган идем.
1993 елда гына разведвзвод командиры лейтенант Мириханов Хафизның 03.10.1943 елда Волхов фронтында һәлак булганы билгеле булды.

М.М.: Икенче **улым Мөҗәһидән** (1927)
**1944** елның августында (17 яше тулганчы) Кызыл армиягә **алына**. Украина, Кырым якларында хезмәт итә. Сугыштан соң да яше җитеп 1951 елга кадәр армия хезмәтендә кала.
Н.М.: Әтиебез Мөҗәһидән (Музагидан) гомер буе сугышта булган һәм хезмәт иткән урыннарын барып күрәсе килеп яшәде. Инде олыгайгач, аңарда яман шеш (рак) авыруы

булуы билгеле булгач, мин Кара диңгез флоты җитәкчелеге белән сөйләшеп, бик яхшы программа әзерләп энем Наил катнашы белән Әтинең хыялын тормышка ашырып өлгердек. Әти тынычланып, зур кунак булып, армиядә хезмәт иткән җирләреннән бик канәгать йөреп кайтты. 2001 елда дөнья куйды.

М.М.: Сугыш дүрт ел буена барды, корбаннар бик күп булды. Совет халкына бик зур авырлык килде. Совет армиясе җиңеп чыкты, көчле немец-фашист армиясен тар-мар итте.

1945 елда сугыш беткәч, 6 июльдә завод мине (Миргарифанны) авыл хуҗалыгы машиналары белән таныш булгач,үзебезнең Тымытык район башкарма комитеты (исполком) карамагына кайтарып җибәрде. Башкарма комитет урып-җыюга транспот начар булгач, мине калхузга бирделәр. Шулай итеп, Тельман исемендәге калхузда, Урсайда  тимер эшләре буенча яңа эш башлап җибәрдем. 1948 еллардан калхузларда эшне механика-машиналаштыру ныгыды һәм халыкка хезмәт хакы түли башлагач, тормыш итү шактый җиңелләште.
Улларым белән 1958 елны яңа алты почмаклы йорт бетереп кердек. Аңынчы дүрт почмаклы бәләкәй генә (5х6м) салам түбәле өйдә яшәдек.
Н.М.: Яңа өйне бураганда мин (Назиф), 6 яшьлек малай зурлар янында йомычка җыеп йөрдем. Миргарифан бабай үкән-сүткәндә сугышта алган яраланудан каткан бармаклары белән: менә, Надиф улым да эшкә ярый

башлады бит, -  дип, аркадан кагып китә иде.
1959 елны миңа мәктәпкә барырга вакыт җиткәч Бабай: “Улымны үзем укытам”, - дип мине Урсай мәктәбенә бирмәкче булган иде. Әти риза булмады.

М.М.: 1961 елны калхузчыларның өйләренә электр уты (электричество) кертелде.

Н.М.: Миргарифан бабайны ир-оныгы тарафыннан авыр эштән “азат итү” соңрак булды. Миңа 16 яшь туласы елны без Әти белән Урсайга печән өмәсенә килдек. Ни эшләптер чалгылар саны ир-атлар саныннан бергә ким иде – мине санамаганнар, тырма тоттырдылар. Мин Бабайның чалгысын сорап алдым һәм чаба башладым, Әти мине өйрәткән иде инде. Карыйм, Бабай бик канәгать, көне буе тырма күтәреп, безне көйләп йөрде. Кич белән арганны бетерә торган даруны - ачы балны Миргарифан бабай миңа үзе салып бирде. Бу көн минем, күмәк эшләрдә катнашу буенча, ир-атлар төркеменә кабул ителүем көне булды.

М.М.: Хәләл җефетем Нурлыбанат Хәлилулла кызы белән сигез бала үстердек. Еллар бик авыр булды. Көндезен калхузда тимерчелектә эшләп, төнен йокламыйча тегү тегеп өс-башларын кайгырттык, ач итмәскә тырыштык. Балаларны, савит хөкүмәтенең кайсы почмагында да эшләрлек булсыннар дип, тырышып укыттык. Һәм эшлиләр дә! Хәдерге көндә карт белән карчык икәү генә яшибез. Үзем Ватан сугышыннан кайткач 3-нче группа инвалит

булып яшәдем. 1961 елда Әлмәт районында (Азнакай районы берзаман Әлмәт районына керде) комиссиядә мине бер файдасыз 2-нче группа гражданский инвалитка күчерделәр. Шул вакыттан бирле калхуздан һәм аул сәвитеннән бер төрле дә ярдәм юк. Елга бер тапкыр бер ситнер (центнер) богдай (бодай) акча түләп алам. Хәдерге көндә барлык пенсия 20 сум, башка юк. Тәмам.

Н.М.: Миргарифан бабай, әлбәттә, пенсиягә чыккач та үзенең умарта асравын һәм һөнәри (ау, мурда, ятмә белән) балык тотуын дәвам итте. 1977 елда вафатына кадәр Урсай авылында мулла булып торды.

Миргарифан бабай үләр алдыннан Нурлыбанат әбигә әйтеп үзенең "Нәсел" язмаларын миңа вәсият итеп калдырган: "Назифта булса алар югалмаслар, онытылмаслар", - дигән.

Язылды: Миргарифан бабай, 1975 ел;
Н.М. - Миргарифанның оныгы Назиф, 2024 ел. (1999 елда "Нәсел -Род", дигән китабым чыккан иде.)

Текста Миргарифан бабайның  уллары Мөҗәһидән (1997) , Фәнис (2003) язган истәлекләр дә кулланылды.

Мөҗәһидән (М.) Миргарифан улы үз тормышы турында.

1927 елның 4 декабрендә Урсай аулында туганмын. Урта белемне, үземне сугышка алганчы Тымытык мәктәбенә йөреп укып, алып өлгердем.
1944 елда, 17 яшь тулганчы, сугышка китеп 1-нче Украина фронтында ай-ярым катнашып аннан Батумига училищега җибәрелдем. Н.М.: 1976 елда Батумида булганда мин (Назиф) ул училищены барып карадым.
1945 елның май аенда сугыш беткәннән соң безне Севастопольгә төрле хәрби частьләргә җибәрделәр. Мин радиолокация частенә билгеләндем. 1941 елдан (14 яшьтән) сугышка алынганчы үзлегемнән өйрәнеп СТЗ тракторында эшләп алган идем. Бу турыда (воинский) частьтә белгәч мине Америкадан килгән “Генераль-электрик” локаторына моторист итеп куйдылар һәм Севастополь янындагы Кача аэропортына билгеләделәр. Анда үзлегемнән укып, Симферополь шәһәрендә шофёр правасы  алдым.
Н.М.: Автомобиль йөртергә өйрәнергә һәм йөртү (вождение) буенча имтихан тапшырырга безнең Әтигә немец әсирләре (пленныйлары) ярдәм иткән. Ул бу турыда сөйләгәндә без, сугыш турындагы кинолардан нимесләрне бик “яхшы” белгән балалар: “Ничек алар белән (өйрәтүчесе кабинада, ике йөк бушатучысы кузовта) машинада чүп илтергә чыгып китәргә курыкмадың?”- дип сорый идек.

М.: Америкадан килгән “БОШ”, “Генераль-электрик” дизель двигателләрен яхшылап өйрәндем, күп кенә сафтан чыкканнарын төзәттем. Аларның кайберләрен 1946 елда Харьков трактор заводына капремонтка җибәрделәр һәм шулар белән мин дә командировкага бардым. Харьков заводында булу миңа киләчәктә Тымытык МТС-ында эш башлап җибәрергә зур ярдәм итте. Ул вакытта Харьков заводында дизель двигателле ДТ-54 тракторлары чыгара башлаганнар иде.
Севастопольдә хезмәт иткәндә Кара диңгез флоты штабы каршында оешкан партия мәктәбен отличнога бетергәч Академиягә билгеләндем. (Н.М.: Әтинең укып алган аттестатларның бөтенесе дә диярлек отличнога иде).
Без икәү идек, Азнакай районы Таллы-Бүләк аулы егете һәм мин. Ул укырга китеп, соңгы көнгә кадәр хезмәт итеп вице-адмирал булды. Хәзерге көндә Севастопольдә отставкада. Мин укырга китмәдем, аның өчен мине ачуланучылар да булды ( нач. штаба вице-адмирал Бондаренко).

Н.М.: 35 ел чамасы узгач Академия мәсьләсе тагын килеп чыкты. 1985 ел башында мине (Назифны) Академиягә укырга чакырдылар. Тулы исеме – СССР Хөкүмәтенең Халык хуҗалыгы Академиясе. Туп-туры Әти янына киңәшкә кайтып киттем. Чөнки без Роза белән институтларны тәмамлагач Әти-Әниләргә, үзебезнең аулга иң якын булган эш шәһәре - Әлмәткә сайлап кайткан идек. Әти берни уйлап-сорап тормыйча, безнең Мәскәүгә укырга китүне хуплады. Четерекле ягы шунда иде, Академиядән соң яшь

җитәкчеләрне Мәскәү үзе яңа эш урынна, илнең кайсы регионына, союздаш республикасына кирәк - шунда билгели. Безнең туган аулдан ерак китмичә яшәү шуның белән бетәчәк иде.
Әти аргумент буларак үзенең ничек Академиягә китмичә калган үкенечен сөйләде. Тәкъдим иткән вакытта Академиядә укыган булсам адмирал булыр идем, хәзер аулда сыер күте чокып ятмас идем, диде. Ә ул чынлап та мин кайтканда шул эш белән шөгыльләнә иде: сыерның арт ягын ветеринар әйткәнчә пинцет белән кортлардан чистарта да дару сөртә, чистарта да сөртә.
Мин Академядән соң Мәскәүдә калып “адмирал” дәрәҗәсендәге зур эшләрдә эшләп Әтинең “хатасын” төзәттем, гомүмән, аңа зур горурлык китердем.

М.: Мин 1951 елның 10 апрелендә демобилизоваться ителеп, туган якка кайтып, 01.05.1951 ел Тымытык МТС-ына автомеханик булып эшкә кердем. Шул ук елны 19 сентябрдә өйләндем. 1 октябрдә Казанга А\х (Аул хуҗалыгы) министрлыгы оештырган, МТС-ларга җитәкче кадрлар хәзерләү курсларына җибәрелдем һәм 1953 елда аны тәмамлап кайтып Тымытык МТС-ында баш инженер булып эшли башладым. МТС каршында тракторист, комбайнёрлар курсларында ир-атлар укыттым, чөнки МТС-та механизатор кадрларның 40%-ты хатын-кызлар иде. 1958 елда министерство аркылы Йошкар-Олага (Мари-Эль) ике елга укырга киттем  һәм 1960 елда тәмамлап кайткач башта МТС директоры, аннан соң

“Сельхозтехника” управляющие булып 1972 елның 13 мартына (45 яшькә) кадәр эшләдем.

Н.М.: МТС-лар “Сельхозтехника” дип атала башладылар. Безнең Әти тугыз ел эчендә механиктан МТС диреторына кадәр барып җиткән икән.

М.: 1972-90 елларда Тымытык мәктәбендә механизаторлар хәзерләү буенча оештрылган Азнакай СПТУ филиалын җитәкләдем (зав. филиалом). Филиалда укыган кешеләргә, мәктәп укучыларына тракторист, комбайнёр, шофёр, мотоцикл йөртү таныклыклары бирелде. Алар хәзерге көндә дә якын-тирә колхозларда эшлиләр.

Н.М.: Тормышның Әти белән мине тоташтырган тагын бер бик күзгә ташланмаган ягы турында язып үтәсе килә:
9-нчы классны бетергәч мин Тымытык сабан туенда яшьләр арасында көрәш буенча батыр калдым. Колхоз машинасы белән берничә көрәшче арасында мине Бакалы сабан туена да алып барып йөрделәр әле. Казанда укыганда классик көрәш секциясенә йөри башладым (1969-72 еллар). Бервакыт шулай Бауман урамындагы безнең чиркәү-спортзалда тренировка бара, карыйм тренер (Матвеев) янында Әти утыра, бик тәмләп аралашалар. Казанга эш белән килгән икән, минем көрәш белән шөгыльләнүгә бик канәгать булды. Ул үзе дә сабан туйларында гер күтәрү буенча бүләкләр ала иде, көрәшкәләп тә карады. Бер елны сабан туена кайтып мин Тымытык аулында батыр калдым. Ул вакытта авырлык категорияләре юк иде әле, финалга

мин һәм 120 килолы бер баһадир калдык. Әни атылып чыгып мине җитәкләп мәйданнан алып чыгып китмәкче була, Әти һәм хөкемдарлар (судьялар) аны тынычландыралар. Без көрәшә башладык, маташа торгач классик алым белән (подсидка, отрыв от земли за счёт выпрямления ног и одновременный резкий подбив с крутым мостом) бу баһадирны аякларын өскә күтәртеп күкрәк аша ыргытып аркасына салдым. Бөтен мәйдан гү килде, Әти йөгереп чыгып мине күтәреп алды һәм шул килеш мәйдан әйләнде. Ул көнне Әти кичкә кадәр  аул буйлап мактанып йөрде. Караңгы төшкәч кенә эзләп  алып кайттык. Аул (элекеге район үзәге) сабан туе батыры, әлбәттә, спортта зур уңыш түгел. Әммә монда сүз аталар һәм балалар арасында була торган җылылык һәм горурлык мизгелләр турында.

Бу истәлекләрен Әти 1990 елның июлендә Тымытыкта минем сорау буенча язып бирде.
Мөҗәһидән Миргарифан улы 2001 елда 74 яшендә вафат булды, Казанның “Тынычлык” бистәсе зияратында тормыш иптәше Мәфрүзә Миңнулла кызы белән бергә җирләнгән.

Н.М.: Газизулла бабай Кәрамуллин (1927-2009) - тормыш иптәшем Розаның Әтисе.

Газизулла бабай шәҗәрәсенең җиде буын ирләр тармагы: Галиәкбәр – Ногман – Кәрамулла – Хикмәтулла (1898-1943) – Газизулла – Илдар (1955) – Марсель - ...
Ногман - ясаклы татар, тегермән тоткан, өч хатыны булган. Аның балалары: беренче хатыннан - Хөҗҗәт, Ислам; икенче (Мәхбүбә исемле) хатыннан - Кәлимулла, Шәйхелислам, Хәбибә (1872), Мөслимә (1874), Төхбәтулла (1876); өченче хатыннан - Кәрамулла.
Кәрамулла бабай белән Шәмсевафа әби балалары: Хикмәтулла (1898-1943), Шәмсебану (1901), Фәтих (1905-1942), Нурия (1910), Миңнесафа (1913).
Алга таба Газизулла бабайның үз язмаларын да бирә башлыйм (Г.Х.):

Мин, Газизулла Хикмәтулла улы Тымытык районы Югары Стәрле аулында 1927 елда туганмын. Әтием Хикмәтулла Кәрамулла улы (1898), гражданнар сугышында катнашкан. Ватан сугышы башлангач колхоз рәисе булып торды, 1942 елда сугышка китте, !943 елның октябрендә Смоленск якларында һаләк булды.

Н.М.: Без, Назиф, Роза һәм улыбыз Ильнур 2015 елны Хикмәтулла бабайның һәлак булган урынына барып баш иеп кайттык. Җирле музейга аның турында мәгълүмат калдырдык.

Г.Х: Әнием Кәримә (1902) гомере буе колхозда эшләде, 93 яшендә Азнакайда вафат булды.
Н.М.: Кәримә әби тугыз бала тапкан: Галиәкбәр (1925-43), Газизулла (1927-2009), Миңнехаҗи (1930-69), Әнәс (1936-48), Тәлгать (1939-2024), Әнвәр (1942-92), бер кызы һәм ике игезәк уллары бәләкәй чакта үлгәннәр.
Хаҗи абый, Стәрле колхозы зоотехнигы, 39 яшендә юл һәләкәтендә вафат булды. Тәлгать абый Азнакай нефтчеләренең бер оешмасында озак еллар партком секрктаре булды. Әнвәр абый - агроном, райиспокомның авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләде.
Кәримә әби Розаның бик яраткан дәү әнисе иде. Роза мәктәп елларында җәйге каникулларын  гел Әбисе янында Югары Стәрледә уздырды.

Г.Х.: Кәрамулла бабамның  кызы Шәмсебану, аның кызы Миңнезифа улы Сәйфетдинов Тахир Әгъзяевич (1950-2007) гомер буе хәрби хезмәттә булып авиация генерал-лейтенанты дәрәҗәсенә җитте.
Н.М.: Генерал Сәйфетдиновның соңгы хезмәт иткән урыны Брянск шәһәре булды. Мәскәүгә эш белән килгәндә минем янга кергәләп йөрде. Аны генерал-плковник Акчурин Рәсим Сөләйманович (1931) яхшы белә иде. Мин (Назиф) Тахир Әгъзяевичка отставкага чыккач Брянск Татар милли-мәдәни автономиясен оештырырга тәкъдим иткән идем. Кызганычка каршы, генерал кардәшебез 57 яшьтә яман шеш (рак) авыруыннан үлеп китте. Азнакай музеенды аңа багышланга стенд һәм экспонатлар бар.

Г.Х.: Кәрамулла бабамның кызы Нурия, аның кызы Махира улы Абдрашитов Зиннур Зәйнетдинович (1952) Азнакайда зур гына автоцентр “Вираж” хуҗасы, бокс буенча тренер һәм  халыкара категорияле судья. Н.М.: 2021 елда Зиннур кардәшебез дә яман шеш (рак) авыруыннан үлде.

Н.М.: Газизулла бабайның туганнан туганы Кәрамуллин Җәүдәт Фәтих улы (1940) көрәш буенча күп еллар Югары Стәрле сабан туе батыры булып торган. Газизулла үзе дә яшь чагында сабан туйларында ярыйсы гына бил алышкан.

Хикмәтулла бабайның сеңлесе Миңнесафа кызы Мәйсәрә (1951) белән Роза Газизулла кызы бәләкәйдән үк бик дус булып бергә үстеләр. Роза белән Мәйсәрә Назиф белән Назилга кияүгә чыктылар. Бу очракта, Назил - Сарлы егете.

Г.Х.: Стәрле мәктәбен бетергәч аттестат алырга имтиханны район үзәге Тымытыкка (ач килеш 22 км җәяү) барып бирдек. Стәрле аул советына салым (налог) агенты булып эшкә урнаштым. Аул советы бик зур иде, советка кергән һәр аул 10-15 чакрымда урнашкан. Менә шул араларны җәяү йөреп ач-ялангач халыктан салым, заем,  һәртөрле башка түләүләр җыю белән шөгыльләндем.
1948 елны мине Совет Армиясенә алдылар. Башта Саратовта бер ел укыдым, радиотелеграфист белгечлеге алдым. Уку беткәч Австриягә җибәрделәр. Сугыштан соң бу илдә бераз Совет гаскәре калдырылган иде. Пассажир поезды белән алып киттеләр. Львов шәһәрендә берничә сәгать тордык. Вокзалда кая карама белдерү, мөрәҗәгатъ –

бендеровчыларга бирелергә кушканнар. Юлда барганда күрдек: каршы якка таба тәрәзәләре тимер рәшәткәле, ишекләре тыштан бикләнгән, кая карама сакчылар булган вагоннарда эшелон-эшелон яшьләр Себер киттеләр. Австриядә өч ел булдым. Ул илдә бик яхшы яшиләр, культура югары, аракы эчмиләр, сугышмыйлар. Мин аннан ике мәртәбә ялга кайттым. Австриядән киткәндә биек таудан әкренләп төшкән сыман буласың. Мәскәүдә дә хәерчелек, эчү, вокзалларда тәртипсезлек. Безнең якларга кайта-кайта мескенлек һаман арта да арта.
Икенче мәртәбә ялга кайткач Һидаяны очраттым. Ул безнең аул мәктәбендә укыта иде. Минем аны 1947 елны армиягә киткәнче күргәнем бар иде инде, күрше аул мәктәбе укытучысы буларак. 1951 елның октябрендә өйләнештек, 1952 елның сентябрендә кызыбыз Роза туды. Шул ук елның октябрендә өйгә Стәрлегә кайттым.
Аул советында элеккеге эшемдә эшли башладым. Бераз эшләгәч Тымытык райкомына эшкә чакырдылар, мин 1947 елда ук партиягә кергән идем инде. 1954 елдан ВЛКСМ (комсомол)-ның Тымытык райкомына беренче секретарь (җитәкче) итеп куйдылар. 1955 елда улыбыз Илдар туды. 1956 елда Казан югары партия мәктәбенә (ВПШ) укырга җибәрделәр. 1959 елда кызыбыз Әлфия туды. 1960 елда ВПШ-ны тәмамлагач (КПСС-ның) Азнакай райкомына Пропаганда, агитация бүлеге мөдире итеп куйдылар. Ул вакытта гаилә белән Тымытыкта яши идек әле.
1962 елны райком тәкъдиме белән мине Тымытык, Әгер,

Күктәкә аулллары җирләрен биләп торган “Авангард” колхозы рәисе итеп сайладылар. Мин 1955 елдан ук Казан аул хуҗалыгы институтының агрономия факультетында читтән торып укый идем инде. Бу белемем дә исәпкә алынды. Шулай итеп, районда иң яшь (35 яшьлек) һәм бердәнбер югары белемле колхоз рәисе булдым. Район структураларында эшләгән тәҗрибәм һәм таныш-белешләр күп булгач колхозда эшләр әйбәт китте.
1964 елда ул замандагы Ил (СССР) башлыгы Н. Хрущёв безнең якларга килде. 10 август көнне “Авангард” колхозының кукуруз басуында булдык. Хрущёв кукуруз арасында рәхәтләнеп йөрде, аңарда кукуруз өчен горурлану күренеп тора иде. Урманда төшке аш вакытында Хрущёв минем белән әңгәмә (сораштыру) уздырды. Миңа сезнең якларда бик ошады, тагын килермен әле, дип китте Хрущёв.

Н.М.: Ләкин Хрущёвка безнең якларга яңадан килергә язмаган иде. Шул ук елның октябрендә Брежнев группасы аны эшеннән алды.
Ә 10 августка әйләнеп кайтсак, мин (Назиф) ул көнне колхоз идарәсе янында кызыл пионер галстугы тагып салют-честь бирергә әзер булып постта тордым. Әммә Хрущёв колхоз идарәсе янында туктамыйча ачык “Чайка” автомобилендә узып китте. Без кул болгап кына калдык. Киенеп-ясанып торган чибәр һәм алдынгы сыер сауучылар Хрущёв өчен махсус пешерелгән чәкчәкне дә тапшыра алмый калдылар. Аны колхоз рәисенең тормыш иптәше Һидая ханым пешергән булган, аңа кызы Роза ярдәм иткән. Ул чәкчәк

белән уңыш бәйрәме мәҗлесендә колхозчыларны сыйлаганнар.
Хрущёв киткәч икенче көнне “Правда” газетының беренче битендә Хрущёв- Кәрамуллин әңгәмәсе басылып чыкты.
Г.Х.: 1969 елда мине Ленин ордены белән бүләкләделәр һәм  Азнакай райисполкомы рәисе урынбасары итеп сайладылар. Анда өч ел эшләгәч Колхозара төзелеш оешмасына (МСУ-га) башлык итеп куйдылар.

1973 елда Роза үзе белән бергә уйнап үскән Тымытык егете Назифка кияүгә чыкты, алар Әлмәттә яши башладылар. Мин Әлмәт шәһәр партия комитетына күчтем, бераздан Әлмәттә төзелә торган батырма насослар заводына (АЗПН-га) директор урынбасары итеп күчерделәр. Һидаяның чире һаман көчәйде, врачлар һава алыштырырга кирәк дигән карарга килделәр. “Радиоприбор” заводының Кырымдагы ял базасында алты елга якын булдык. Мин ул базаның хуҗалык мөдире вазифаларын башкардым. Һидаяга анда гел әйбәт иде. Н.М.: Без дә Роза һәм балалар белән Әти-Әни янына Кырымга “Жигули” автомобилендә Әлмәттән сәяхәт ясадык. Чулпан кызыбыз җәен бөтенләй Кырымда үткәрде.

Г.Х.: Польша белән сугыш хәленә җиткәч Әлмәткә кайттык, “Радиоприбор” заводына урнаштым.

1985 елны кияүнең эше буенча Розалар Мәскәүгә күчеп киттеләр. 1989 елда Һидая (60 яшендә) үлгәч Тымытыкта җирләдек. 1990 елда Азнакайга кайттым.

Бүгенгесе көндә Мәскәүдә яшим.
Кәрамуллин Г.Х., 2007 ел.

Н.М.: Розаның Әнисе Һидая ханым тумышы белән Сарман районы Мортамак авылыннан, бик абруйлы укытучы һәм чибәр хатын-кыз иде.
Хәзерге вакытта (2024) Газизулла әфәнде (1927-2009) белән Һидая ханымның (1929-1989) уллары Илдар хатыны Гөлфая белән белән Чаллыдан күчеп Минзәлә районының Тулбай аулында бик матур гына яшәп яталар. Гөлфая ханым - журналист, Миргарифан бабайның нәсел язмаларын беренче булып (1981) гарәб графикасыннан кириллицага күчерде. Кызлары Ләйсән һәм уллары Марсель Чаллыда яшиләр. Ләйсәннең уллары - Сөләйман һәм Тамерлан.

Газизулла белән Һидаяның кызлары Әлфия Мәскәүдә яши. Озак еллар инде Федерация Советында Татарстаннан җибәрелгән сенаторланың ярдәмчесе булып әшли. Ире Альберт (1957-2019) белән ике балалары бар - Раушания һәм Рамиль. Раушания ире Булат белән Казанда яши, балалары - Әмир, Мәрьям. Рамиль белән хатыны Алинаның уллары - Селим.

Яза торгач бер гаҗәп хәлгә игътибар иттем:
Әтиләребез Мөҗәһидән һәм Газизулла биографияләрендә шактый тәңгәллек бар. Икесе дә 1927 елда Тымытык районында туган, 1951 елда армиядән шактый тормыш тәҗрибәсе туплап 24 яшьтә туган авылларына кайтып

өйләнгәннәр: Мөҗәһидән - сентябрдә, Газизулла - октябрдә. 1952 елда балалары туган: Назиф - августта, Роза - сентябрдә. Икесе дә гаиләләре белән район үзәге Тымытыкка җитәкче эшкә күчеп килгән. Олы балаларына 10 яшь тирәсе булганда бер урамда (Ленин урамында!) яши башлаганнар.
Шунда без, Назиф белән Роза, бер-беребезнең дөньяда бар икәнен белдек, бергә уйнап-аралашып йөри башладык. Тагын 10 ел үткәч, Казанда институтларны тәмамлап Тымытыкка кайтып туебызны уздырдык.
Менә, шуннан соң ничек язмышка ышынмыйсың. Безнең әтиләр, хәттә югары җитәкче эштә эшләүләрен дә, икесе дә 45 яшь тирәсендә туктатканнар. Партияга да бер вакыттарак (1947) кергәннәрен язып тормадым инде. Олыгайган көннәрендә икесен дә кызлары карады: Мөҗәһидән бабайны - Фәйрүзә. Газизулла бабайны - Роза белән Әлфия.

Бәлки, әтиләребез бер төрлерәк хезмәт һәм тормыш юлы узганга безнең Роза белән дөньяга карашыбыз шактый якын булгандыр?!

Н.М., 2024.

Миңнулла бабай Нәбиуллин - Әниебез Мәфрүзәнең Әтисе.

Урсай аулында, чыгышы белән Казан ягыннан булган, күп балалы игенче Нәбиулла Нәфигулла улы гаиләсендә 1898 елда туган. Үз җирләре аз булганлыктан күпчелек байларга батраклыкта эшләгәннәр. Шуңа карамастан Миңнулла аулның, Миргасим хәзрәт мәчет каршында ачкан, башлангыч мәктәбендә белем алган. Миңнулланың Әнисе Махибәдәр хәзерге Мөслим районы Чакмак аулыннан булган.

1914 елны Миңнулланы Беренче бөтендөнья сугышына алалар. Анда әсирлеккә (пленга) эләгеп дүрт ел Австрия алпавытының (помещикның) плантациясендә эшли. Россия әсирләрен алпавыт сарайда салам өстендә йоклата, ашауны начар ашатмый. Революцияләр узып, Брест солыхы (договоры) кабул ителгәч әсирләр белән алмашканнан соң Миңнулла Кызыл армиягә эләгә. Бер хәрби операция вакытында Чапаевны күрә.

Башына “будённовка” кигән кызылармеец Миңнулла туган аулына 1922 елны гына кайта. Аны бушап калган җимерек өй каршы ала, Әти-Әнисе, сигез бертуганы 1921 елгы ачлыктан үлгән булалар. Ике сеңлесе Рауза белән Миңнур гына көчкә исән калганнар. Миңнулла бабай батрак булып эшли башлый. Сеңлесе Раузаны хәзерге Мөслим районы Мухан аулы кешесенә кияүгә бирә. Аул картлары Миңнулланы ялгыз хуҗалык тартучы Нәгимәнең кызы Бибихаҗәргә димлиләр. Ике як та риза булып, Миңнулла

сеңлесе Миңнурны җитәкләп бу йортка кияү булып керә. Тора-бара Миңнурны батрак Галимәрдәнгә кияүгә бирәләр. Аларның балалары: Бибисара, Маһинур, Мәүлитҗан (1949). Миңнулла белән Хаҗәр (1903) әйбәт кенә яшәп китәләр. 1925 елны кызлары Рәхимә, аннан безнең Әни Мәфрүзә (1926), уллары Кыям (1929) һәм Сафуан(1931), кызлары Мәгъмүрә (1933) туа. Уллары Индус бәләкәй  чагында үлә.

1938 елны колхозның орлыкка дигән 500 центнер бәрәңгесе өшегәч агротехник Миңнулланы халык дошманы (враг народа) дип төрмәгә утырталар. 1939 елны Бабай төрмәдән ирекле рәвештә (доброволец булып) “Хәсән күле” (Халхин-гол) сугышына китә. Анда яраланмагач гаебе акланмый һәм ул сугышны финнар белән дәвам итә. Фин сугышында күрсәткән батырлыгы өчен вакытыннан алда акланып 1941 елны төрмәдән кайта.
Өендә ике ай да яшәргә өлгерми Ватан сугышы башлана. Миңнулланы Белоруссия фронтына алып китәләр. Башта разведвзводта хезмәт итә, немецларның тылына чыгып “тел” алып кайткады өчен (за взятие “языка”- пленного для допроса) “Кызыл Йолдыз” ордены белән бүләкләнә. Разведкада яра алмаган Миңнулла чагыштырмача тыныч көнне снайпер пулясын эләктерә. Зур гәүдәле Миңнулла иелеп йөрүдән арып окоптан башын чыгара һәм шул ук мизгелдә каршы яктан ату тавышы яңгырый. Снайпер пулясы аның башын тишеп чыга. Уң як яңагыннан керә, арткы тешләрен чәрдәкләп сул як яңагыннан чыгып китә. Бабай безгә яңакларындагы ул җөйләрне (шрамнарны)

күрсәтә иде. Каршы яктан аткан немец снайперы мылтык прикладына тагын бер сыр ясап куйгандыр инде, тагын бер совет солдатын үтердем дип.
Госпитальдән соң Миңнулланы сапёрлар взводы командиры итеп куялар. Взвод сугышка кышлаклардан алынган русча аңламый торган үзбәкләрдән җыелган. Алар күперләр салу, күперләрне шартлату, юлларга, басуларга миналар кую һәм миналардан чистарту эшләре белән шөгыльләнгән. Аңлашу буенча бер кыенлык та булмаган, үзбәкләр татар телен шактый яхшы аңлыйлар бит. Бабай: иң кыены дошман бомбага тотканда иде, ди. Бомбалар төшә башлагач, төрле якка сибеләсе урынга, үзбәкләр барысы бер урынга җыелып бер-берсенә сыенып ятканнар. Шуңа күрә бик күпләп кырылганнар.
Сапёр бер генә тапкыр ялгыша диләр, - Миңнулла бабай ялгышкан: минага баскан... Салкын сарайда мәетләр (трупы) арасында аңына килгән. Аны балчык арасыннан иптәшләре казып алган булган. Уң аягының үкчәсе нык кына (пятка с лодыжкой) умырып алынган була, аяк бармаклары сеңгерләрдә генә асылынып торган (висели на сухожилиях). Санитарлар жгут салып хирургларга алып кайтып биргәннәр. Наркозсыз гына аркылы пычкы белән аягын кискәндә Бабай үлгән сыман була. Аны хирург “конвейерыннан” алып моргка чыгарып куялар. Салкын һавадан ул аңына килә һәм үзен мәетләр арасында күреп кычкыра башлый. Алып кереп аягын тагын өстәнрәк кисәләр, инде гангрена башланган була.

1943 елны шыгырдап троган Америка протезын киеп 45 яшьлек Миңнулла аулга кайта. Ул протезга өйрәнеп бетә алмыйча үзенә агач аяк ясап кия һәм гомер буе шуның белән йөрде. Ә без бәләкәй чакларда чын аякка ошаган Америка протезы сарай чардагында безне куркытып эленеп тора иде.
1945 елга кадәр Бабай колхоз рәисе булып эшли, аннан үзенең сугышка кадәр булган агротехник эшен дәвам итә.

Н.М.: Мин (Назиф) тугач Әни (Мәфрүзә) бала карарга җайлырак булыр дип беразга үз әти-әнисенә күчкән. Әти (Мөҗәһидән) укуда була. Миңнулла бабайны аул сәвитенә миңа докумен алырга җибәрәләр. Бабай Нәбиуллин Назиф дигән туу турында таныклык күтәреп кайта. Мин туганда әле Әти-Әни аул сәвитендә (ЗАГС-та) язылышмаган булалар. Шулай итеп, минем беренче фамилиям Нәбиуллин булган.

Пенсиягә чыккач Нәбиуллин Миңнулла “алачыкта тәгәрмәч сукты” - мастерскойда ат арбаларына тәгәрмәчләр ясады, “чана табаннары бөкте” -  ат чаналары ясады (гнул полозья). Башыннан узгән кеше чыдамсалык авырлыкларга карамастан Миңнулла бабай һәрвакыт оптимистик рухлы, ачык күңелле, шаян, җор кеше булып калды.
Миңнулланың тормыш иптәше Бибихаҗәр Әби Нугайбәк нәселеннән булган Әхмәтшәкүр (1874-1910) кызы була. Хаҗәр әбинең Әнисе - Нәгимә әби (1876-1949) Югары Стәрле аулыннан тире эшкәртүче Галиулла кызы. Урта хәлле Әхмәтшәкүр хатынын 14 бала белән калдырып 36 яшендә үлеп китә. Ул балаларның 12-се 1921 елны ачлыктан

интегеп җан бирәләр. Ачлыктан исән калган 10 яшьлек Мөхәммәднәҗип Ыкны чыбык төягән арба белән ерып чыкканда, арба ауып йөк астында кала һәм суда тончыгып үлә. 19 яшьлек Хаҗәр Әнисе Нәгимә белән генә кала. 1924 елда Миңнулла белән Хаҗәр өйләнәләр, ике хатын-кыз тарткан хуҗалыкта ир-ат барлыкка килә.

Миңнулла бабай (1898-1987) һәм Һаҗәр әби (1903-1998) олыгайган көннәрендә Азнакайда кызлары Мәгъмүрә (1933-2024) тәрбиясендә яшәделәр.
Гитлер Германиясен җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан Миңнулла бабай “Бөек Ватан сугышы” ордены белән бүләкләнде. Без, оныклар, Миңнулла бабайны “Биш сугышта катнашкан аксак бабабыз” - дип йөртә идек.
Миңнулла бабай оныклары: Рәхимә ападан - Рәсимә, Зөбәйдә, Әнис, Марат, Салават; Әниебез Мәфрүзәдән – Назиф, Назил, Фәйрүзә, Наил; Кыям абыйдан - Хәмзә, Хәлил (бәләкәй чакта үлде), Дилбәр, Зөһрә; Сафуан абыйдан – Илсөяр, Әлфия; Мәгъмүрә ападан - Ильдус, Гөлфирә, Лүзә. Рәсимә, Зөбәйдә, Әнис, Хәмзә – гүр ияләре. Марат белән Салават Азнакайда яшиләр. Салаватның бер кызы Казанда гаиләсе белән үз өендә яшәп ята. Урсайда Миңнулла бабай йорты нигезендә Кыям абый балалары яши.

Бу биографик язмаларның төп өлешен 1990 елда Урсайда Миңнулла бабай һәи Бибихаҗәр әби сөйләвеннән язып алдым. Роза да минем белән иде.

Н.М. - 1990, 2024.

Йомгак урынына (Вместо послесловия).

Миргарифан бабай язмаларында милли мәсьәләләрләр турында берни дә язылмаган. Җирле төрки халык нугайлар, башкортлар, типтәрләр, мишәрләр, керәшеннәр, (ясаклы) татарлар, казан кешеләре дип этник төркем атамалары белән бирелә. Бу төркемнәрнең сөйләм телләре бер-берсеннән бераз аерылса да патша һөкүмәте алар белән административ эшне, бигрәк тә казак хезмәтен уртак төрки-татар әдәби телендә алып бара. Ул заманда (иске) татар теле чит илләр белән аралашу өчен Россиянең икенче дипломатик дәүләт теле булып та торган. Мәчетләр каршындагы мәктәпләрдә дә укыту, бераз гарәб-фарсы сүзләре белән баетылып, шушы телдә алып барылган. Миргарифан бабай язмалары үз эченә 18 - 20 гасырларда булган вакыйгаларны ала. Бу вакыт эчендә татар һәм башкорт халыклары этногенезында шактый үзгәрешләр булды.

Язмада күрсәтелгән этнонимнар бүгенге халыкларның һәм этник группаларның исемнәрен нигезләү яки инкар итү өчен кулланыла алмый. Ул вакыттагы атамаларны бүгенге милли мәсьәләләрне хәл итүдә уңай яктан гына исәпкә алыйк, төрки халыкларның бердәмлеген, дуслыгын ныгытуда кулланыйк.

Н. М., 31.12. 2024.

Чыганаклар, әдәбият:

1. Миргарифан Мирихан улы. Нәсел һәм заман. - Урсай, 1976. Гарәб алфавитында татарча кулъязма. Бердәнбер данәдә Назиф Мириханов архивында саклана, Мәскәү.

2. Назиф Мириханов. Нәсел – Род, (70 с.) – Москва, 1999. Ротопринт – рукопись.

3. Трепавлов В.В. Заключение о шеджере Н.М.Мириханова. Инст. Рос. истории РАН, письмо №14105 от 17.09.1996. -М.

4. Научный архив Петербургского Института востоковедения . Фонд 131 (Риза Фахретдинов): опись1, дело 50, с. 34а-б.

5. Опись рукописей Института...(ИЯЛИ) АН РТ. Фонд 99, опись 1, дело 93. Шеджере. - Казань. (М. Әхмәтҗанов).

6. Назиф Мириханов. Полпред. Вәкил: Статьи, интервью, выступления, (400), - М.: Голос-Пресс, 2016. (Есть в Инете).

7. Имангулов И.В. Энергия предков, (420 с.) – Уфа, 2020. (Шеджере Нугайбека - Шамсутдина - ...) il.iman@yandex.ru

8. В.Белов. Заглянем в глубину веков, (540 с.) – Елабуга, 2015. (Шеджере Нугайбека - ...) vik1969_10@mail.ru

9. Татарская Энциклопедия, том 4. – Казань, Инст. ТЭ, 2008. (Мириханов Назиф, Нугайбековы - дворяне.)

10. Трепавлов В.В. История Ногайской Орды, (750 с.). - М: Изд. РАН, 2001.

11. Н. Мириханов. Ногайская Орда как неотъемлемая часть истории РФ./Газета “Татарские новости”, №8, 2008. – М.

12. Марсель Әхмәтҗанов. Татар халкы оешуда нугайларның катнашы. /”Идел” журналы, №3-4. – Казан, 1992.

13. Роберт Зарипов. Туган төбәкне өйрәнәбез. /“Маяк” газеты, №№135, 140; 10,19 ноябрь, 1996. – Азнакай.
(Урсай аулын 1670 елны Урсай бабай нигезләгән).

14. Мортазин Зөфәр. Чалпы аулы тарихы. Чалпы, 1967. Кулъязма, машинкада бастырылган китап.
(Сыйнфый караш: бай Нугайбәк нәселе ярлы халыкны изгән.

15. С. А. Алишев. Татары Среднего Поволжья в Пугачёвском восстании, (200 с.). – Казань, Таткнигоиздат, 1973.

16. Вахит Имамов. Сәет батыр. Татарлар Пугачёв яуында. – Яр Чаллы, КамАЗ нәшрияте, 1994.

17. Азнакай -язмышыбыз. Энциклопедия. - Азнакай, Казан, 2014. (Мирихановлар, Г.Кәрамуллин, М.Нәбиуллин).

18. Н.М.Мириханов. Федерализм, этничность, государство: новый курс. рос. власти, (350 с.) - М.: Изд. Арбат Т., 2002.

19. Назиф Мириханов. Трудовые будни, (40 с.). – Москва, 2001. Ротопринт – рукопись.

20. Кто есть кто в татарской общине Москвы, (240 с.). – М.: Изд. Арбат, 2001.

21. Гумилёв Л. Н. От Руси к России: очерки этнической истории. – М.: Изд. Экопрос, 1992.

22. Н. Мириханов. Донские казаки -русские воины татарской конницы (в 13-15 вв.)./«Татарские новости», №10, 2008. -М.